# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

2 / 2021

Татар күн мозаикасы традицияләре белән танышу бүгенге осталар өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы – XXI гасырда иҗат ителгән әйберләрнең бизәкләре һәм төсләре гармониясендә борынгы читекләрнең аһәңе тоемлана






Мир, где творят и правят дети




*Илдар ЮЗЕЕВ*

# Сагышлы *мирас*

*Булганбыз без эре халык, тере халык.*
*Гасырларны кичә-кичә вакланганбыз.*
*Ваклансак та, без һаман да рухи Алып:*
*Тукай булып, Сәйдәш булып сакланганбыз.*
*Ни әйтсәң дә, Алыплардан яралганбыз.*
*Шул нигездә торасыбыз, корасыбыз.*
*Чәчелгәнбез, сибелгәнбез, таралганбыз.*
*Бабайларның бик сагышлы мирасы без.*
*Алып бабай тубалыннан чәчелгәнбез.*
*Үсмәсен дип чиру булып килгән ятлар.*
*Өзелмәслек тамырдан без, нәселдән без,*
*Җанга сеңгән моңсу җырлар, риваятьләр.*
*Ак син, җырым, Әтил сыман дулкынланып,*
*Тыңла, бала, шул дулкынны уйга талып.*
*Бабаң менгән рухи үрдән төшә күрмә,*
*Төшә күрмә, Алыплардан калган халык!*

*1995 ел*





Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Түгәрәк уен

№ 2 2021

16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге



Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова



Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590.
Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 18.06.2021
Чыгу көне: 26.06.2021
Заказ: 016153
Тираж: 1000 экз.



Редакция һәм нәшер итүче:
420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru



«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78



Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта:** И. Гайнетдинов. «Болгар» панносы фрагменты. 2008 ел


© «Түгәрәк уен», 2021


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ


4 **Сабан туе оештыручыларга мең дә бер киңәш**

6 **Мирас. Матурлык**

8 **«Ләмберә татар-мишәрләренең халык көйләре» җыентыгы дөнья күрде**

9 **Ирада Әюпова: «Uen fest» аша балалар виртуаль дөньяның тулы канлы реаль тормыш чагылышы гына булуын аңлады**


## ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ


10 Л. Саттарова
**Казан читеге**


## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ


16 Л. Мөхәммәтҗанова
**Сөрән йоласының мәгънәсе һәм эчтәлеге**

22 Ә. Нурхаметова
**Сабан туе – сынлы сәнгать әсәрләрендә**

27 Р. Гайфетдинова
**Татар Сабантуйсыз булдыра алмый**
*(Бәйрәм логотибы турында)*


## ӘДӘБИ МИРАС



30 М. Шәмсетдинова
**Сагынмак дип бәет яздым...**


## ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...


34 Ф. Мәрданова
**Татар булмый комгансыз**

38 Е. Шемелова
**Питрәч керамикасы һәм Питрәч тәрбиясе**

40 Д. Фәрдиева
**Икмәк салу серләре**
















**СӘХНӘ**

43 Л. Солтанова
**Остазларым**

**МИЛЛИ УЕН КОРАЛЛАРЫБЫЗ**

48 Г. Садыкова
**Арча. Гөслә. «Ятаган»**

**КУНАКХАНӘ**

50 Ф. Лотфуллина
**Айгөл Бариева: «Мөнәҗәтләр көйләү күңелемне тынычландыра»**

**БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ**

54 Н. Зыятдинова
**Яңа китап**

**БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...**

56 **Газиз телем – Тукай теле!**

57 **Туган телем**
**Сабан туенда**

58 **Нурын сибеп торсын исемебез**

59 **Дуслык** *(Җыр)*

**ӨЙ КҮРКЕ – АШ**

60 **Җиде сорау**
**Кычыткан ашы**

**ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ**

64 **Шахворд**

## САБАН ТУЕ ОЕШТЫРУЧЫЛАРГА МЕҢ ДӘ БЕР КИҢӘШ

Сабантуйларны оештыручылар өчен республикада 2003 елдан бирле махсус укулар үтә. Быел ул «Халык бәйрәме Сабан туе: оештыру методикасы һәм технологиясе» семинар-практикумы форматында узды. 36 сәгатьлек укыту программасында 16 лекция, 15 осталык дәресе һәм мәдәни чаралар каралган иде. Укулар онлайн һәм оффлайн форматта алып барылды.

Оештыручылар – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге.

Семинарларда онлайн рәвештә 1500 кеше катнашкан, шуларның 70е – төрле чит илләрдән. Ә 50 кеше катнашу өчен Казанга килде. Килүчеләр лекцияләрдән тыш, республиканың Арча һәм Апас районнарына сәфәргә чыктылар, мәдәни программа буларак, Г. Камал театрында Мансур Гыйләҗевнең «Исәнмесез!?» спектаклен, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Алтын Казан» мюзиклын тамаша кылдылар. Шулай ук Габдулла Тукайның тууына 135 еллыгы уңаеннан Арча районының Яңа Кырлай авылында узган Шигърият бәйрәмендә дә катнаштылар. Биредә кунакларны Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев сәламләде. Аларга ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең «Сабан туе – хезмәт туе» дип аталган мастер-классы тәкъдим ителде, Арча пешекчеләре гөбәдия пешерү серләре белән бүлеште.





Укуларның теоритик өлеше Казанда – ТР Милли китапханәсендә үтте. Лекцияләрне тарих фәннәре докторы, профессор Гамирҗан Дәүләтшин, Аксубайның төбәкне өйрәнү музее директоры Әлфия Нурхаметова, Татарстан Милли китапханәсенең фәнни һәм методик эшләр буенча директор урынбасары Ирек Һадиев, сәнгать белеме докторы, профессор Гүзәл Сөләйманова-Вәлиева, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луиза Фәсхетдинова укыды.

Эвент-менеджер, халыкара дәрәҗәдәге бик күп чаралар оештыручы Азат Галәмшин бәйрәм оештыру менеджменты турында сөйләде – тыңлаучылар фикеренчә, аның чыгышы семинарда булган иң кирәкле һәм мөһим дәресләрнең берсе иде. Борынгы милли бәйрәмебезне ничек заманчалаштырырга, анда яшьләрне, башка милләт кешеләрен ничек җәлеп итәргә, чараны кызыклы һәм халыкка якын итәр өчен нинләр эшләргә, чарага акчаны каян табарга һәм нәрсәгә финансларны җәлләмәскә – спикер шушы мөһим сорауларга җавап бирергә тырышты.

Чираттагы мастер-класста кунакларны Татарстанның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле солистлары, республиканың атказанган артистлары Айгөл Кыямова һәм Раил Ганиев татарча зәвыклы итеп биергә дә өйрәтте.

Сабан туе бәйрәменең прологын катнашучылар Апас районы мисалында өйрәнде: биредә милли бәйрәмебезнең җирле үзенчәлекләрен чагылдырган тамаша тәкъдим ителде. Биредә программа лекцияләр белән дәвам итте. Режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Халисә Исмәгыйлева семинарчыларга Сабан туе бәйрәме-



нең режиссурасы хакында сөйләде. Казан дәүләт мәдәният институтының театраль иҗат кафедрасы доценты Азат Зарипов исә Сабан туенда милли уеннар темасына тукталды. Мәдәни программа буларак, кунакларга районның Туган якны өйрәнү музеена экскурсия һәм халык театры тарафыннан сәхнәлештерелгән «Диләфрүзгә дүрт кияү» спектакле тәкъдим ителде.

Семинарның соңгы көннәрендә сәнгать белгече Гүзәл Сөләйманова милли бәйрәм киеме турында, Россия Көрәш федерациясенең спорт директоры Илнар Галиев милли көрәш хакында сөйләде, Сабан туен үткәргәндә мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлеккә Татарстан Республикасы Мәдәнияти министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы Рәйсә Сафиуллина тукталды. «Mardesign» заманча этник дизайн студиясе җитәкчесе Айдар Мәрданшин исә бәйрәм логотибы турында онлайн лекция укыды.

Укуларда катнашучыларга махсус сертификатлар тапшырылды.





## МИРАС. МАТУРЛЫК

**Галим, сәнгать белгече, тарихчы, архитектор Фоат Вәлиевнең (1921-1984) тууына – 100 ел**

Дөнья глобальләшеп барганда милли традицияләрне саклап калу аеруча мөһим. Монда галимнәрнең, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең роле гаять зур: алар милләтнең рухи һәм иҗади потенциалын ача. Фоат Вәлиев шундый шәхесләрнең берсе. Ул халыкның декоратив сәнгать һәм архитектурасындагы югары казанышларын өйрәнеп, аларны кешелек дөньясына таратып, гомерен татар халкына хезмәт итүгә багышлаган.

Республикада галимнең 100 еллыгы уңаеннан фәнни-гамәли конференция узды, «Татар халык декоратив сәнгате» китабы җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде, «Мирас һәм хәзерге заман» күргәзмәсе үтте.

«Хәзинә» милли сәнгать галерeясында ачылган күргәзмәдә Фоат Вәлиев экспедицияләрдә туплаган һәм музей коллекцияләре нигезендә ясалган декоратив һәм гамәли сәнгать әсәрләренең график реконструкцияләре күрсәтелде. Шулай ук, монда халык декоратив сәнгате традицияләрен дәвам итүче хәзерге заман рәссамнарының иҗаты да урын алган иде. Тамашачы шамаил, металл эшкәртү, каюлы күн (күн мозаикасы), укалап чигү (алтын җепләр белән), керәч (керамика) сәнгатьләре һәм агачтан уеп ясалган әйберләр белән таныша алды.

Күргәзмәдә тәкъдим ителгән күпчелек рәссамнарның иҗатында яңа популяр тенденцияләрдә традицияләрне милли уникаль күзаллау белән автор стилен берләштерү тәҗрибәсе чагылды. «Татарча casual» (Айгөл Сингатуллина), нәфис керамика (Әлфия Зубкова), Ринат Әхмәтов, Наилә Кумысникова, Алсу Мусавирова, Айгөл Садриева, Айрат Шәмсетдинов, Рөстәм Шәмсутов һәм башкаларның уникаль автор эшләнмәләре шундыйлардан иде. Уникаль күргәзмә әсәрләре арасында «Туран Арт» (Суфия Хәйбрахманова житәкчелегендә), «Сәхтиян» (Илдус Гайнетдинов, Әлфия Артемьева), «AyBulgari» (Айгөл Садриева) кебек халык сәнгате предприятиеләре һәм массакүләм тиражланган дизайнер продукцияләре булды.

Кайбер әсәрләр иске үрнәкләрнең репликалары буларак (Э. Дәүләтшина, С. Кузьминых, Р. Мөхәммәтшин, Л.Фәсхетдинова), икенчеләре традицион образларны үзләште-

реп ясалган. Авторның оригиналь формасы халык иҗатының колористик, бизәкле һәм ритмик төзелешенә нигезләнгән: болар – Р. Әхмәтовның декоратив паннолары һәм бизәнү әйберләре, Алсу Мусавирова, Алсу Сингатуллинаның һәм «AyBulgari» остаханәсендә иҗат ителгән дизайнер эшләнмәләре, Наилә Кумысникованың бизәкле кояш паннолары, Рөстәм Шәмсутовның керамикадан ясалган дивар тәлинкәләре.

Бүгенге көндә күп кенә рәссамнар һәм дизайнерлар милли стильдәге костюмнар иҗат итеп, популяр этник линияне үстерә (Алсу Мусавирова, Алсу Сингатуллина, Айгөл Садриева һәм башкалар). Каюлы кояш (кояш мозаикасы) бизәкләрен стилизацияләү зур урын алды – аларны аяк киемендә генә түгел, кием дизайнында (күлмәкләр, курткалар, футболкалар һәм башкалар), күннән һәм тукымалардан төрле аксессуарлар ясаганда (сумкалар, каешлар, кушаклар, бизәнү әйберләре һәм башкалар) күрергә мөмкин.

Гомумән, күргәзмәдә тәкъдим ителгән әсәрләрдә матурлыкны заманча аңлау чагылды. Алар Татарстанда хәзерге сәнгати образларны формалаштыруда һәм аның милли үзенчәлегендә мөһим роль уйный.





**Белешмә:**

*Фоат Вәлиев берничә дистә ел дәвамында республикабызның татар авылларында, шулай ук, Әстерхан, Кырым экспедицияләрендә халык сәнгате, орнамент, костюм, күпсанлы татар кәсепләре буенча бай материал туплаган галим. Ул беренчеләрдән булып Казан татарларының XVIII-XX гасыр башы халык декоратив сәнгате, Идел буе Болгар, Казан ханлыгы, Казан татарларының халык сәнгате һәм архитектурасы буенча зур күләмдәге материалны җыя, өйрәнә һәм системалы рәвештә гомумиләштерә. Фундаменталь академик тикшеренүләр булган 8 китап, 100 дән артык фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр авторы. Аның «Татарстанның халык декоратив сәнгате» исемле соңгы китабы Казанда 1984 елда дөнья күрә. Галим вафатыннан соң аның хезмәтләре кызы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова тарафыннан фәнни редакцияләнә һәм бастырып чыгарыла.*



## «ЛӘМБЕРӘ ТАТАР-МИШӘРЛӘРЕНЕҢ ХАЛЫК КӨЙЛӘРЕ» ҖЫЕНТЫГЫ ДӨНЬЯ КҮРДЕ






Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «Ләмберә татар-мишәрләренең халык көйләре / Народные песни лямбирских татар-мишарей» фольклор җыентыгы тәкъдим ителде. Китапның авторлары Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләрне саклау ресурс үзәгенең халык иҗатын үстерү бүлеге мөдире, сәнгать фәннәре кандидаты Лилия Җиһаншина һәм Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе доценты, сәнгать фәннәре кандидаты Лилия Сәрвәрова.

**Белешмә:** *Музыкаль басма укучыларны Мордовия Республикасында яшәүче һәм әлегәчә этномәдәни үзенчәлекләрен саклап кала алган ләмберә татар-мишәрләренең музыкаль-шигъри традицияләре белән таныштыра. Җыентыкка кертелгән җыр үрнәкләре 2014-2015 елларда Мордовиянең Ләмберә районында, Казан консерваториясе оештырган фольклор экспедициясе кысаларында язып алынган. Җыентыкка ноталары белән бергә 86 җыр үрнәге кергән. Шигъри текстлар диалекталь үзенчәлекләрне искә алып төзелгән һәм рус теленә юлга-юл тәрҗемә ясалган. Җыентыкка CD-диск беркетелгән. Китапның бер бүлегенә туй җырлары, икенчесенә – солдат озату җырлары, өченчесенә уен җырлары, дүртенчесенә бәетләр, бишенчесенә лирик җырлар кергән.*

Милли китапханәдәге музыкаль кичә авторларның китапны әзерләү тарихы белән таныштыруыннан һәм Лилия Җиһаншина башкаруында ләмберә татарларының «Кыз йылату» көеннән башланды. Мордовиядән килгән «Дуслык» фольклор ансамбле «Айнюк бәете»н башкарды. Ансамбль җитәкчесе Р.А. Ипкәева коллектив белән таныштырды.

Килгән кунакларны һәм барлык тамашачыларны танылган галим, Татарстан Республикасының төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте Советы рәисе Альберт Борһанов, Казан дәүләт консерваториясе проректоры Юрий Карпов, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләрне саклау ресурс үзәгенең директор урынбасары Гөлназ Латыйпова сәламләде. Шулай ук, Мордовиядән килгән туган якны өйрәнүче тарихчы, журналист Ирек Биккинин, Казан дәүләт консерваториясе доценты Геннадий Макаров һәм консерватория профессоры Сәгыйть Хәбибуллин чыгыш ясады.

Музыкаль чыгышларны Алиш исемендәге Балалар иҗат сараеның «Ак калфак» татар фольклор ансамбле «Зәрия» җыры белән, Чувашиядән килгән «Мишәр» фольклор-эстрада ансамбле «Сүгән яр» җыры белән дәвам итте. Казан консерваториясенең фольклор ансамбле «Киндерләр җәйдем» җырын тәкъдим итте.

Музыкаль кичә Лилия Җиһаншина җитәкчелек иткән «Зәкәрия» фольклор төркеменең «Әбделмән купич» лирик җыры һәм Лилия туташның үзе башкаруында «Казаннарда тайлар асырыйлар» җыры белән тәмамланды.

## ИРАДА ӘЮПОВА: «UEN FEST» АША БАЛАЛАР ВИРТУАЛЬ ДӨНЬЯНЫҢ ТУЛЫ КАНЛЫ РЕАЛЬ ТОРМЫШ ЧАГЫЛЫШЫ ГЫНА БУЛУЫН АҢЛАДЫ




«Uen fest» Татарстан халыкларының традицион уеннары республика фестивале 2020 елның 1 августыннан старт алды. Фестиваль үткәрелү турында мәдәният министры Ирада Әюпова үзе игълан иткән иде.

«Әлеге проектны коллективыбыз белән бергәләп уйладык. Ишегалларында балалар тавышы яңгыравын ишетәсе килә, шулай ук гаилә мохитендә дә аралашу җанлансын иде. Без социаль челтәрләрдә милли уеннарыбызның китапханәсен булдырырга уйладык, моның өчен махсус каналлар ачтык. Монда Татарстанда яшәүче мордва, рус, татар, чуваш, мари һәм башка халыкларның уеннарын күреп булачак.

Виртуаль дөньяда яшибез, өлкән буын гореф-гадәтләрне күпмедер дәрәҗәдә белсә дә, яңа буын традицияләребезне белмәүдән, аралашу булмаудан интегә. Бергәләшеп уеннар уйнау бер-береңә ышанычны арттыра, гаиләне берләштерә, уңай хис-кичерешләр тудыра», – диде ул.

Проектка Татарстанның мәдәни оешмалары: театрлар, ансамбльләр кушылды. Артистлар ишегалларына барып, халыкка уеннарны күрсәтә башлады, борынгы уеннарның күп төрлелеге, аларның барлыкка килү тарихы хакында сөйләде, теләге булганнарны уеннарга өйрәтте. Фестиваль, әлбәттә, Казан белән генә чикләнмичә, республикадагы 1 меңнән артык ишегалдына күчте.

Башта балалардан оешкан командалар уеннарының видеоязмасын махсус хэштэг белән социаль челтәрләргә урнаштырып барды, шулай итеп проект карамагында 100 меңнән артык видео барлыкка килде. Бу видеолар флешмоб буларак барса, май аенда катнашучылар гран-при өчен көч сынашты. Финалга 101 катнашучы чыкты. Алар арасыннан җиңүчеләр Казан Кремленең Туп сарае мәйданчыгында, 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көнендә, игълан ителде.

Фестиваль шартлары буенча гран-при иясенә генә юллама бүләк ителергә килешенгән булса да, финалга җиткәндә җиңүчеләр файдасына шартларга үзгәрешләр кертелде. Барлык призерлар да – унбишәр кешедән торган дүрт команда – Әлмәттән «Әпипә», Ютазыдан «Ивушки», Чүпрәледән «Мишәрләр» һәм Саба районыннан «Зәлидә» – Мәскәүнең тематик паркына барып ял итәчәк. «Алла бирса, киләсе елга пандемия бетсә, кешеләрне Диснейга җибәрербез», – дип вәгъдә бирде министр.

Шулай итеп экспериментал проект булган «Uen fest» фестиваленең беренче циклы тәмамланды.

«Бу – халык уеннары фестивале. Безнең миссия – балаларны гаджетлардан аерып үзләренә ышанычларын арттыру. Алар гаджетларда утырып виртуаль дөньяга ышаналар, гаделлеккә ышансыннар – командада көчләрне дөрес бүлеп җиңүгә омтылсалар, җиңә алачакларына инансыннар. Бу дөньяда иң мөһиме – аралашу, җылылыгыңны яныңдагы кешеләргә бирү», – диде Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова.



Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

*Лилия САТТАРОВА,*
*сәнгать белгече, Татарстан Республикасы Милли музееның генераль директор урынбасары*

# КАЗАН *читеге*



КАЗАНДА ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН ДАНЛЫКЛЫ АЗИЯ АЯК КИЕМЕ ҮРНӘКЛӘРЕ РОССИЯНЕҢ КҮПЧЕЛЕК МУЗЕЙЛАРЫН БИЗӘП КЕНӘ КАЛМАГАН, ДӨНЬЯ МУЗЕЙЛАРЫ БУЙЛАП ТА ТАРАЛГАН. АЛАРНЫҢ КАЗАН, КАСЫЙМ ҺӘМ ӘСТЕРХАННАН БАШЛАП, МӘСКӘҮ, САНКТ-ПЕТЕРБУРГ, СЕРГИЕВ ПОСАД, КАЛУГА ҺӘМ ТОРЖОК КЕБЕК РОССИЯ ШӘҺӘРЛӘРЕНДӘ, ИСТАНБУЛ ҺӘМ АНКАРА, ТОРОНТО, ОФФЕНБАХ-АМ-МАЙН КЕБЕК ДӨНЬЯ МУЗЕЙЛАРЫНДА БУЛУЫ – ТАТАР ЧИТЕКЛӘРЕНӘ ҺӘМ ЧҮӘКЛӘРЕНӘ ИХТЫЯҖ ЗУРЛЫГЫН КҮРСӘТӘ.

Бизәкле аяк киеме җитештерүнең чәчәк аткан чоры XVIII гасыр ахырыннан XX гасыр башларына туры килә. Казан сәнәгатьчеләре XIX йөзләрдә үз продукцияләрен Европа башкалаларындагы халыкара күргәзмәләргә куеп югары бәя алган. Абруйлы күргәзмәләрдәге Азия аяк киеме үрнәкләре Европа музейларында һәм шәхси тупланмаларда сакланып калган. Шулай итеп, Казан осталары теккән бизәкле аяк киемнәре игътибарга, тикшеренүгә һәм шуның нәтиҗәсе буларак, коллекцияләрдә сакланырга лаеклы әйберләр исәбенә керә. Россиядә беренче бизәкле итекләр Император Александр III Рус музееның Этнография бүлегенә 1906 елда кабул ителә – бу хакта Инвентарь кенәгәсенә теркәп куелган: «Кострома губернасында эшләнгән, «аскы ягы төрле төстәге сафьяннан үсемлек рәвешендәге кисемнәр белән бизәлгән читекләр – шәмәхә төстәге сафьян итекләр», И.Н. Виноградовтан алынган», – дип язылган. Казанда бизәкле аяк киеме үрнәкләрен җыю белән бераз соңрак кызыксына башлыйлар.

Казан коллекцияләрендә бизәкле читекләрнең кайчан һәм ничек барлыкка килүен күзәтү кызыклы. Имам Салих Галиевның татар һәм шәрыкъ әйберләре коллекциясендә аяк киеме үрнәкләре юк – бу тупланманы этнограф Мәрьям Гобәйдуллина җентекләп тасвирлаган. Леон Сиклер тупланмасына да бизәкле күн кертелмәгән, музейга бу тупланмадан хатын-кыз бизәнү әйберләре, чигүләр, сөлгеләр, кием предметлары һәм традицион баш киемнәре генә күчкән. Бизәкле татар аяк киемнәре ул вакытларда коллекцияләнергә һәм өйрәнелергә тиешле предмет буларак каралмаган.

Беренче татар бизәкле аяк киеме музейга 1920 елда эләккән һәм Шәрыкъ халыклары мәдәнияте күргәзмәсенә куелган. Күргәзмә юлкүрсәткечендә болай язылган: «Ука һәм энҗе белән чигелгән татар аяк киеме коллекциясе, читек өстеннән киешле бәрхет һәм күн башмаклар – кәвешләр, ир-ат һәм хатын-кыз читекләре, йомшак итекләр. Чигешле һәм төрле төстә – хатын-кызларныкы, каралары – ир-атларныкы»[1]. Шунысы да игътибарга лаек – Шәрыкъ халыклары музеена татар әйберләрен җыю халыкның мәдәнияте һәм көнкүреше әйберләрен һәм, аерым алганда, данлыклы читек җитештерү үрнәкләрен дәүләт дәрәҗәсендә коллекцияләргә туплый башлау буенча борылыш еллары була. Алга таба музейның татар коллекцияләрен формалаштыру эшен этнограф Николай Воробьев һәм сәнгать белгече Петр Дульский дәвам итә. Безнең музейның бизәкле күн коллекциясенең нигезен тәшкил иткән беренче экспонатлар Николай Воробьев экспедициясеннән кайткан. «1923 елда Мәскәүдә узачак Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсе өчен Н.И. Воробьев тарафыннан җыелган татар аяк киеме һәм баш киеме коллекциясе» исемлегендә «Арча кантоны һәм Казан татарлары» дигән билге куелган. Музейга барлыгы 16 пар күн аяк киеме



[1] Выставка культуры народов Востока. (Путеводитель по выставке). – Казань, 1920. – С. 40.







кабул ителгән, алар арасында читек җитештерүнең гаҗәеп үрнәкләре бар. Беренче чиратта кара күннән бизәкләнмичә эшләнгән борынгы ир-ат читекләре игътибарны җәлеп итә. Йомшак табанлы читекләр кәвеш белән киелгән. Әлеге читекләрнең үзенчәлекле детале – үкчәнең бизәкләп киселгән яшел саурдан булуы. Моның татар җөе белән тегелгән бик борынгы читек булуына шик юк – ул XVIII гасыр ахырларына карый. Ир-ат читекләренең үкчәсе борын-борыннан Урта Азиядән кайтарылган тупас шигрин күннән – саурдан ясалган. Эчке ягы нечкә һәм вак итеп кискәләнгән ат яки ишәк тиресенә тыгыз итеп тары тутырганнар; кипкән ярманы бушаткач, ярмаланып торган матур өслек барлыкка килгән; бакыр чүбе белән буягач, шигрин күн затлы яшькелт-фирүзә төсенә кергән. Саур чыдамлыгы белән аерылып торган. Борынгы ир-ат читегенең үкчәсенә яшел саур кызыл һәм ак җепләрне чиратлаштырып «шахмат» җөе белән беркетелгән.

Н.И. Воробьев тырышлыгы белән музейда XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында җитештерелгән аяк киемнәре үрнәкләре саклана: яссы табанлы тради-





цион бизәкле читекләр, шулай ук, модалы итекләр һәм үкчәле туфлиләр. Берничә генә пар аяк киеменнән торган бу коллекциядә һәр экземпляр бәһасез. Алар буенча без җитештерүнең ассортименты, кәсепнең искиткеч сыйфаты, иң популяр бизәкләр турында фикер йөртә алабыз. Мәсәлән, вензельле итекләр беренче карашка Азия аяк киеме җитештерүнең табигый продукциясе булып күренми: балтыр бизәкләре көрән төстәге күннән тегелгән, алар көмеш җепләрдән татар җөе белән тоташтырылган. Бу бик оригиналь чишелеш – биредә күннең бертөслелеге белән җөйнең көмеш ялтыравы кушылган, ул график вензельне хәтерләтә, бу, мөгаен, шул чордагы шәһәр парча күлмәкләре модасына туры китереп ясалгандыр.

Күп төсле итекләр һәм читекләр җитештерү гаять популяр булып, алар Кавказга, Урта Азиягә, Төркестанга һәм Себергә, шулай ук, Россиянең эре ярминкәләренә озатылган. Төрле төстәге күннән балаларга да читекләр тегелүен искә алсак, алар шактый кыйммәт булуга карамастан – 1886 елда, мәсәлән, бер пары 12 сум торган – читекләрне олысы да, кечесе дә кигән дип әйтә алабыз.

Үз вакыты өчен модалы булган бизәкле туфлиләр традицион конструкция, орнамент белән эшләнгән. Башмаклар – каты табанлы һәм үкчәле күн туфлиләр – борынгы заманнарда йортта да киелгән һәм купшы аяк киеме дә саналган. Безнең коллекциядәге үрнәкләргә «XX йөз башында тегелгән» дип күрсәтелгән, табанына эшләп чыгаручының өчпочмаклы мөһере дә сугылган («Казаков һәм КО ширкәте. Азия аяк киеме һәм баш киеме җитештерү һәм сәүдә итү. Казан, Мәскәү ур. 57/13»), әмма алар элеккечә борынгы оригиналь өлге буенча ясалган: туфлинең арткы һәм алгы өлешләре тегелмәгән, берсе өстенә берсе куеп беркетелгән. Бу алым, чыннан да, бик борынгы, ул өйдән чыкканда йомшак читекләр өстеннән тупас тиредән тегелгән каты табанлы аяк киеме киюгә бәйле. Күн аяк киеменең кәвеш дип аталган аерым бер төре Казанда җитештерелгән. Чынлыкта бу аяк киеме башмакларга охшап торган: үкчәсе дә булган, кайчакта ул үкчә шактый биек эшләнгән, төсле күн, чигеш һәм чуклар белән төрлечә бизәлгән. Тарихчы Н.И. Костомаров аларны нәкъ менә «башмак» дип сурәтли, аларның да читекләр кебек төсле бизәкле булуын яза. Урта Азиядә күн туфлиләр әле бик озак вакытлар «казонча» (Казандагы кебек) дип аталып йөртелгән.

1925 елда Парижда утәчәк заманча



**10-13 нче битләрдәге фоторәсемнәрдә – 1923 елгы Мәскәү Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсе өчен Н.И. Воробьев җыйган читекләр һәм туфлиләр**





**Парижда үткән Заманча декоратив һәм сәнәгать сәнгате халыкара күргәзмәсендә Татарстан Республикасы экспозициясе. 1925 ел.**

декоратив һәм сәнәгать сәнгате халыкара күргәзмәсенә кую өчен Н.И. Воробьев һәм П.М. Дульский кабат татар әйберләре җыйганнар. Петр Дульский татар сәнгате әйберләрен җыюда һәм популярлаштыруда зур роль уйнаган шәхес. Ул ясаган татар декоратив сәнгате стендының ниндиерәк булуын шул чор фотосурәте аша күзалларга була: әлеге стенд татарларның аяк киеме һәм баш киеме җитештерү промыселы, алтынлап чигү һәм ювелир һөнәре, башка төр продукция турында тулы мәгълүмат бирә. Воробьев һәм Дульский тарафыннан Париж өчен җыелган Татар әйберләре коллекциясе исемлегендә 62 предмет күрсәтелгән – сөлге һәм эскәтер, челтәрле кәрнизләр, намазлыклар, аякчу, тастымал, пыяладагы шамаилләр, баш киемнәре, төймәләр һәм каптырмалар, хәситә, шулай ук 10 пар аяк киеме – көмеш белән чигелгән Азия туфлиләре, вензельле һәм кәгазь белән чигелгән күн итекләр.

Экспедицияләр Казан татарларының традицион сәнгате һәм һөнәрләре турында күбрәк белергә, халык сәнгате артефактларының сәнгати кыйммәтен аңларга мөмкинлек биргән. 1925 елда Мәскәүдә – СССР халыкларының үзәк нәшриятында П. Дульскийның «Искусство казанских татар» дип аталган брошюрасы басылып чыга, биредә ул әлеге сәнгать төренең тулы тасвирламасын урнаштыра. Татарның бизәкле аяк киеме Казан татарларының мәдәнияте һәм көнкүрешенә багышланган музей коллекцияләрендә лаеклы урынын ала һәм ТАССР Үзәк музееның 1925 елда ачылган Этнографик бүлегенең нигезен тәшкил итә.

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасы Милли музееннан алынды

# Бергәләп бизибез!



*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш гыйльми хезмәткәре*

# СӨРӘН ЙОЛАСЫНЫҢ *мәгънәсе һәм эчтәлеге*

СӨРӘН – ИДЕЛ БУЕ ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ КҮБЕСЕНӘ ТАНЫШ ЙОЛА. УЛ ЯЗНЫ КАРШЫЛАУ БӘЙРӘМНӘРЕНЕҢ БЕРСЕ, КАЛЕНДАРЬ-ЙОЛА ФОЛЬКЛОРЫНА КАРЫЙ, БОРЫНГЫ ЧОРЛАРГА УК БАРЫП ТОТАША. БУ ЙОЛАДА ХАЛЫК ТОРМЫШЫ, КӨНКҮРЕШ, ХУҖАЛЫК, МИФОЛОГИЯ ҺӘМ ЙОЛА ПОЭТИКАСЫ, ТЕЛ, ФОЛЬКЛОР ҖӘҺӘТЕННӘН ШАКТЫЙ КИҢ ЧАГЫЛЫШ ТАБА.

Бүгенге көндә татарларда Сөрән йоласы тулы көченә яши дип әйтү дөреслеккә туры килмәс иде, йола үзе дә, аны башкару белән бәйле күп кенә элементлар да әкренләп онытылуга таба бара. Йоланың үзе белән чагыштырганда, аңа бәйле терминология күпкә озынрак гомерле – «сөрән» сүзе һәм бу сүз кергән гыйбарәләр татар телендә бүгенге көндә дә актив кулланыла. Нинди мәгънә аңлата соң ул «сөрән» сүзе?

Сөрән – тарихи хәрби термин буларак «яу чабу алдыннан кычкырып хәбәр салу», «хәвефле хәрби сигнал», «көчле кычкырып хәбәр бирү» дигәнне аңлаткан. «Тору» сүзе белән янәшә килгәндә «каравыл тору», «сакта тору» дигән мәгънәгә ия булган, ягъни хәрби кешенең сөрән торуы ул – хәвеф барлыгын хәбәр итеп, кычкырып аваз салырга әзер тору дигән сүз. Этнографик термин буларак карасак, Сөрән – яз һәм җәен корылык яисә гарасатлы яңгырлар була калса, явыз рухларны куу йоласы; шул йолага чакырып аваз салу. Диалектларда бу сүз, кычкырып кая да булса чакырып йөрү мәгънәсендә, әле дә бик актив кулланылышта. Әйтик, Сабан туе бәйрәменә чакырып, Сабан туенда ат чабышына чакырып сөрән салалар, ягъни өндәп, аваз салып йөриләр һәм башкалар. Болардан тыш та «сөрән» сүзенең «сөрән сугу», «сөрән чабу», «сөрән кычкыру», «сөрәнгә йөрү», «сөрәнләү», «сөрәнче», «сөрән ае» гыйбарәләрендә туры һәм күчерелмә мәгънәләре бик күп. Игътибар итсәк, «сөрән» сүзендә һәм составына бу сүз кергән башка синтаксик төзелмәләрнең тамырында «тавыш», «аваз» мәгънәләрен белдергән борынгы төрки сүзе «өн» ята булса кирәк.

**Мирный бистәсендәге Каенлыкта Сабантуй. Казан, 2017 елның 15 июле. О. Тихонов фоторәсеме. https://m.realnoevremya.ru/galleries/1984**





**Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондларыннан (22 тасв., 335 сакл. бер.)**

Сөрән бәйрәме уздыру Урта Идел, Чулман, Урал буенда яшәүче халыкларга мәгълүм. Чувашлар аны «серен», удмуртлар «сурен», марилар «сюрем», башкортлар «һөрән» диләр.

Идел буе регионында Сөрән апрель аенда уздырыла торган булган. Малны көтүлеккә куар алдыннан һәм чәчү башланганчы яшүсмер егетләр, атларга атланып, авыл урый, авылдагы һәр капка алдында туктап, кычкырып, язны сәламли торган булганнар. Алар килгәндә хуҗалар, бик күптән кабул ителгән гадәт буенча, йортларыннан чыкканнар, яшүсмер малай-шалайны яңа пешкән камыр ризыклары, башка төрле тәм-том белән сыйлаганнар, алып чыккан йомыркаларын тапшырганнар, бүләкләр биргәннәр. Киләсе елның уңышка бай ел булуын теләп, алгышлар әйтелгән, югары көчтән ярдәм сорау башкарылган. Сөрән йоласы белән килгән төркемнең башында малайлардан күпкә олы, кулына «сөрән таягы» дип аталган озын колга тоткан ир кеше йөргән, аны «сөрәнче» дип атаганнар. Шул колгага кешеләр үз өйләреннән бүләккә дип алып чыккан сөлге-тастымалларын, яулыклар элгәннәр.

Ир-ат һәм егетләрнең ат өстендә йомырка һәм бүләкләр җыеп йөрүе яисә кичен, бәйрәмнән соң, өй саен сыйланып йөрүе «сөрәндә йөрү», «сөрән йөрү» дип аталган. Иртән сөрәндә йөргәндә дә, кичен дә махсус җырлар башкарылган. Алар «сөрән җырлары», «сөрән көйләре», «сөрән сугу көйләре» дип аталганнар. Шундый җырлардан татарларда бүләк биргән өчен рәхмәт әйтү һәм яхшы теләкләр теләү характерындагылары сакланып калган. Әйтик:

*Безләр килдек сезләргә,*
*Бүләк бирерләр дип безләргә.*
*Бүләкләр бирсәгез безләргә,*
*Озын гомер телим сезләргә.*

Сөрән йоласының ни рәвешле үтүен искә төшерә алучылар әле бүгенге көндә дә бар. Татарстанның Мамадыш районы инфор-

манты йола тәртибен түбәндәгечә тасвирлый: «Элек үткәргәннәр ул Сөрәнне. Зур учак яга торганнар иде елга буенда. «Иртәгә Сөрән, аннары телән!» – дип кычкыралар иде. Олылар: «Әнә, дәрә кычкыралар!» – ди торганнар иде. Аннан атка атланып ир-ат, бала-чага килеп җитә. Сөрән җырлары ди торганнар иде инде, җырлап киләләр:

*Озын чыршы бүрәнә,*
*Чаналардан сөйрәлә.*
*Җиңги, кая тастымалың,*
*Муенга салсам, сөйрәлә.*

Кем нәрсә чыгарып бирә сөрәнчеләргә. Бирмәсәң, ачуланып та җырларлар иде. Бирсәң, рәхмәт әйтеп җырлыйлар инде:

*Безләр килдек, ай сезләргә,*
*Тастымаллар бирдегез безләргә,*
*Тастымаллар бирдегез, ай, безләргә,*
*Аллаһ саулык бирсен сезләргә.*

Сөрән таягына беркетәләр тастымалларны. Икенче көнне иртән мәйданда бәйрәм була торган иде. Җыйган бүләкләрен шунда батырларга өләшәләр. Әле кичен сөрән йөрү була торган иде. Җырлап килеп керәләр хәл сорашып. Ашау-эчү инде, сыйланалар хәленчә. Күңелле була торган иде».

Күргәнебезчә, йола фольклорга хас синкретиклык сыйфатларын үзенә туплаган. Сөрән йоласында акцияләр, ягъни төрле хәрәкәтләр, гамәлләр бар, вербальлек, ягъни сүз сөйләү, поэтика, музыкальлек бар, предметлар (сөрән таягы, йомыркалар, тастымаллар һәм башкалар) шулай ук йола процессында катнаша.

Мәйданга җыелган халык күңел ачкан. Бәйрәмдә көрәш, төрле уеннар, ярышлар узган. Сөрән таягына капка саен еленә барып җыелган тастымал һәм яулыкларны алып, җиңүчеләргә өләшкәннәр. Сөрән йоласының ахырында язгы кыр эшләре алдыннан һәм гомумән, яз җитү, ягъни яңа көн туу алдыннан чистарыну йоласы уздырыла торган булган. Зур мәйданда учак якканнар. Йола үтәүдә катнашучы яшь-җилкенчәк янып яткан учак аша сикерү ритуалын башкарган, болай эшләү кеше башына килергә мөмкин бәла-казалардан, явыз рухлардан арындыра, чистарыну бирә дип санаганнар булса кирәк. Мондый йола үзенә күрә көч, кыюлык, җитезлек, уңганлыкны-булганлыкны, батырлыкны һәм егетлекне сынау булып та торган.



**Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондларыннан (22 тасв., 336 сакл. бер.)**



**Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондларыннан (22 тасв., 334 сакл. бер.)**

Кайбер информантлар искәртүенчә, учак янында җыелганның соңында өйдән өйгә сыйланып йөрү гадәте дә булган. Алда әйтеп кителгәнчә, «сөрәнгә йөрү» дип аталган бу гадәтнең эчтәлеге кеше саен кереп, сыйланып чыгудан гыйбарәт булган. Бәйрәмнең бу өлешендә дә җырлар башкарылган, мәсәлән, ике якның әйтешеп сөйләшүе формасындагы түбәндәге җыр кызыклы:

– Әби, бабай, сез иминме?
Аш-тәгамнәр салдыгызмы?
– Ашларыбыз әзер, оланнар,
Утырыгыз, оланнар!

Сөрән җырларының текстлары бик гади, лексик составы ягыннан караганда аларны архаик җырлар дип әйтергә мөмкин булыр иде. Ә көйләре речетатив характерга ия, шулай ук бик гади. Сакланып калган сөрән җырлары мәҗүси чорда билгеле бер функция үтәгән борынгы йола җырларына карый. Үзләренең структуралары белән сөрән җырлары берничә өлештән торган. Хуҗаларны сәламләүдән гыйбарәт җырларны кереш җырлар, сүз башлау өлеше дип билгеләргә мөмкин. Йоладагы җырларның төп өлешен яз килү уңаеннан алгыш-теләкләр яудыру, хуҗалардан бүләк сорау, сый-хөрмәт таләп итү алып торган. Йоланы хөрмәтләп бүләкләр биргән, кунакларны сыйлаган хуҗаларга рәхмәт әйтү, яхшы теләкләр теләү, ә инде бүләк эләкмәсә, хурлап җырлау йомгаклау җырлары дип бәяләнә. Җырлар гадәттә ачык һавада башкарылган, борынгы заманда магик эчтәлеккә ия булган. (Болар хакында карагыз: Мөхәммәтҗанов Р. Эзләсәң – табыла. Казан утлары, 1977, № 9, б. 57; Альмеева Н.Ю. К определению жанровой системы и стилевых пластов в песенной традиции татар-кряшен // Традиционная музыка народов Поволжья и Приуралья. Казань, 1989, с. 10-11; Исхакова-Вамба Р.А. Татарское народное музыкальное творчество (Традиционный фольклор). Казань: Татар. книж. изд-во, 1997, с. 23-24.)

Шунысын әйтергә кирәк: Сөрән йоласы белән Сабан туе йоласы бер-берсенә тирән керешкән мәҗүси, ә бәлки ярыммәҗүси бәй-

рәмнәр. Мәҗүси дигәндә бу очракта катгый рәвештә ниндидер потларга табыну дип аңлау дөрес булмас иде. Гомумән, татарларның мәҗүсилектән килә торган бәйрәмнәре дигәндә халыкның исламгача ук гореф-гадәтендә булган, күп очракта исламга бөтенләй катнашы булмаган борынгы йолаларны күздә тотабыз. Сөрән йоласында да, Сабан туе бәйрәмендә дә ислам белән бәйләнгәнлек юк, әмма күп кенә элементларында шул ук ислам белән параллель бара торган ниндидер бер уртаклык тоемлана, болар халыкның ислам кабул ителгәннән соңгы чор көнкүреше белән әллә ни каршылыкка кермиләр кебек. Бу борынгы йола бәйрәмнәре асылда халыкның көнкүреше белән тыгыз бәйләнгән. Аларның нигезендә яз башлануга уңышлы ел сорап күктәге көчкә мөрәҗәгать итү ята, дип билгеләү дөрес булыр. Сөрән белән Сабан туен алда торган язгы кыр эшләре берләштерә.

Билгеле булганча, Идел буенда Сабан туе да элек язгы кыр эшләре алдыннан уздырыла торган булган. «Сабан ае», «сабан тургае», «сабан ашлыгы» төшенчәләрендә «сабан» сүзе борынгы чорда йолдызларга бәйле календарь нигезендә яз башына, ягъни май аена бәйле кулланылган, «Сабан туе» төшенчәсе дә шуңа бәйле булырга мөмкин. Сабан ае Кояш Ореон йолдызлыгында булган вакытка туры килгән, Идел буе регионында күкнең көньягындагы бу якты йолдызлыкны апрель-май айларында күрергә мөмкин булган. Сабан ае дигәндә Идел буенда чәчү алды чоры күздә тотылган, димәк, апрель ахыры-май айларына туры килгән. Бу чорда туган балаларга, «Сабан аенда туды», – дип, Сабан дигән исем кушу да «Сабан ае» төшенчәсенең элек актив кулланылганлыгын искәртә.

Сөрән бәйрәме белән Сабан туеның, язгы календарь йола буларак, бер чорга туры килүе тора-бара аларның кушылып китүенә китергән. Сабан туе йоласында, мәсәлән, Сөрән йоласындагы кебек, бүләк җыю элементы мәгълүм. Сөрән йоласындагы кебек, халыкта бу элементны «сөрән сугу» дип атау бар. Я булмаса Сабан туе бәйрәмендә ат чабышы булачагын хәбәр итеп кычкыру да диалектларда «сөрән салу» дип атала. Шунысы шиксез: борынгы чорларда Сөрән йоласы белән Сабан туе йоласы икесе ике бәйрәм буларак авыл саен үткәрелгән.

Кайчандыр архаик җырлар җырлап, магик авазлар чыгарып, антлар кычкырып, юраулар юрап башкарылган Сөрән йоласы, вакытлар узу белән бик нык саеккан, әлбәттә. Моның иң беренче сәбәбе Идел буе татарларында грамоталылыкны, укымышлылыкны, китап культурасын алга сөргән исламның киң таралуы булса кирәк. Исламга кайткан халыкның көнкүреш мәсьәләләренә дә Коръән күзлегеннән карый башлавы гаҗәп түгел, бу исә халыкның моңа кадәр ныклы ышаныч белән үткәрелә торган йолаларына башкача якын килүне таләп иткән, кешенең үз-үзен тотышына үзгәрешләр керткән. Алга таба исә Совет идеологиясенең халык аңына йогынтысы, шулай ук гореф-гадәт һәм йолаларны тирән үзгәртүгә тәэсир ясаган. Сөрән йоласының борынгылык белән сугарылган мәҗүси мәгънәсе һәм эчтәлеге дә әкренләп кысылуга йөз тоткан. Бу йоланы бүгенге көндә дә хәтерләүчеләрнең булуы халыкта Сөрән йоласының тамырлары шактый тирән һәм нык булу хакында сөйли. Халыкның җыр репертуарында Сөрән җырларының, трансформация кичергән рәвешендә булса да, әле дә очравы, яисә халык теленә тирән кергән берәмлекләрнең бүген дә актив кулланылышы моны дәлилли.

Чыганаклар:
1. Баранов Д.А. Символические функции русской колыбели // Славяно-русские древности. Вып. 3: Проблемы истории северо-запада Руси. – СПб., 1995. – С. 235-236.
2. Басаева К.Д. Семья и брак у бурят. Вторая половина XIX – нач. XX века. – Новосибирск: Наука, 1980. – 223 с.
3. Баязитова Ф.С. Гомернең өч туе. Татар халкының гаилә йолалары. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1992. – 295 б.
4. Насыри К. Избранные произведения. – Казань: Таткнигоиздат, 1977. – 255 с.
5. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / Томны төзүче, кереш мәкаләне язучы искәрмәләр әзерләүче Х.Ш. Мәхмүтов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. – 591 б.
6. Татары Среднего Поволжья и Приуралья / Отв. ред. Н.И. Воробьева, Г.М. Хисамутдинова. – М.: Наука, 1967. – 538 с.
7. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: Т.1. (А-Г). – Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

*Әлфия НУРХАМӘТОВА,*
*Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасы атказанган мәдәният хезмәткәре*

# САБАН ТУЕ – *сынлы сәнгать әсәрләрендә*



**Шамил Шәйдуллин. «Озын гомерлеләр». 1997 ел. «Сабантуй» циклыннан. Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее**

*Сабантуй – чын мәгънәсендә милли рух җәүһәре, татар халкының үзенчәлекле мәдәниятының бетмәс-төкәнмәс чишмәсе, аның рухи торышы, һәм талантларны ачу өчен бик яхшы мөмкинлек, җитезлектә, тапкырлыкта көч сынашу....*

***Татарстан Республикасы беренче Президенты***
***М.Ш. Шәймиев***

САБАН ТУЕ – ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ, КОМПОЗИТОРЛАРЫ, РӘССАМНАРЫ ӨЧЕН МӨҺИМ ТЕМА. УЛ БАКЫЙ УРМАНЧЕ, ЛОТФУЛЛА ФӘТТАХОВ, ТАВИЛ ХАҖИӘХМӘТОВ, ИРИНА КОЛМОГОРЦЕВА, ЗӨФӘР ГИМАЕВ ҺӘМ БАШКА КҮРЕНЕКЛЕ РӘССАМНАРНЫҢ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЧАГЫЛДЫРЫЛГАН. БҮГЕН БЕЗ АЛАРНЫҢ КАЙБЕРЛӘРЕНӘ КҮЗ САЛЫРБЫЗ.

**Нәүфәл Адыловның «Сабан туе батыры»**, **Рада Нигъмәтуллинаның «Бәйрәм мизгелләре»** дигән масштаблы скульптуралары бәйрәм рухы белән сугарылган.

**Лотфулла Фәттаховның «Сабан туе»** картинасында беренче күзгә ташланганы – киң мәйданда халыкның кайнап торуы. Рәссам һәр кешенең йөз-кыяфәтен, киемен эзлекле сурәтләп бирә алган.

Алгы планда Сабан туеның таҗы – көрәш сурәтләнгән. Көрәшнең үзәгендә өч кешене күрәбез: икесе – кызып-кызып җан-фәрманга көрәшүчеләр; өченчесе – иңенә сөлге бәйләгән ак сакаллы бабай – аларга хөкемдар ролен үти. Ул көрәшне шулкадәр бирелеп күзәтә, хәрәмләшү булмасын өчен, көрәшүчеләрнең бер генә хәрәкәтен дә күздән ычкындырмый. Өстәл янында утырган, җиңенә кызыл тасма бәйләгән аксакал да үзенең кордашына булыша, көрәшне бик сынап карый. Мәйдандагы башка кешеләр дә көрәшне кызыксынып күзәтәләр, көрәшчеләргә дәрт биреп торалар. Мәйдан хәрәкәтен көчәйтү өчен, андагы киеренкелекне белдереп, рәссам көчле искән җилне, тирәяктагы болытларның кабарынып җыелуларын, агач ботакларының җилгә сыгылып-сыгылып торуын оста итеп тасвирлаган. Болар аша Лотфулла Фәттахов мәйдан ыгы-зыгысын күз алдына китереп бастыра.



**Лотфулла Фәттахов. «Сабантуй». 1957 ел. Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее**



**Фәйзрахман Әминов. «Сабантуй». 1950 ел. Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее**

Җитмешенче еллар ахырында, торгынлык һәм милли нигилизм чорларында да рәссамнар үзләренең картиналарының традицион сюжет сызыгын югалган кыйммәтләр, халык тормышының бетүгә йөз тоткан матур яклары, милли традицияләр хакындагы фәлсәфи уйланулар белән тулыландырганнар. Мәсәлән, **Абрек Абзгильдинның «Капчык киеп йөгерү»**, **«Көрәш»**, **«Капчыклар белән көрәшү»** картиналары шундыйлардан, аларда Сабан туе күренешләре, күңел ачу тамашасы булудан бигрәк, уйга сала, моңсулык иңдерә.

**Шамил Шәйдуллинның «Сабан туе»** картинасында, башкалардан аермалы буларак, уеннар түгел, бәлки мәдәнилек – рухилык, милли мирас, бабаларыбыз дөньясының гүзәллеге – мәсьәләләре куела. Картина нигезендә шашкын хәрәкәтчәнлек урынына декоратив рәвештә бирелгән матурлык ята. Рәссамның келәм рәвешендә тудырылган «Бәйрәмнәр» дигән панносы алдагы әсәрендә кузгалтылган уйлануларының дәвамы буларак кабул ителә һәм йөзләргә, орнаментларга язылган халык тормышы һәм характерлары формуласы кебек укыла.

Үткән гасырның сиксәненче еллар уртасыннан башлап, Сабан туе сюжетлары халыкның рухи уянуы һәм иҗтимагый гайрәте турында сөйли. Аларның кайберләре хәрәкәтләрнең вакыты һәм урыны күрсәтелмәгән ритуал күренешләренә әверелә, рәсемнәрдә билләрен сөлге белән буган идеаллаштырылган Алыплар калка, иярләрендә нәфис батырлар утырган нечкә сыйраклы атлар басып килә – кыскасы, тамаша үлемсез баһадир халык, аның үткәне һәм бүгенгесе турында шагыйрәнә миф-риваяткә әверелә. Моңа мисал итеп, **Рифкат Вахитовның «Болгар җире турында сюита»** картинасын китерә алабыз.

Сабантуй башланырга берничә көн кала «Сөлге җыю» йоласы булган. Сөлгеләрне авыл картларын атка утыртып, яшь егетләр гармуннарда уйнап, җырлап-биеп, күңелле итеп җыеп йөргәннәр. Алар артыннан бала-чага ияргән. Җыелган сөлгеләр белән Сабантуй мәйданын бизәгәннәр, төрле ярышларда җиңеп чыгучыларга бүләк итеп биргәннәр. Бу теманы үз картиналарында **Равил Заһидуллин** ачык тасвирлый (**«Тиздән Сабантуй»** картинасы).



Абрек Абзгильдин. «Көрәш». 1994 ел. «Сабантуй» циклыннан. Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее

**Фәйзрахман Әминов «Сабантуй»** картинасында авыл күренешләрен, ат чабышын, халык образларын төгәл сурәтли.

Сабантуйның иң абруйлы ярышы, әлбәттә, ат чабышы. Сабантуйлар ат чабышларыннан башланып киткән һәм бу традиция әлеге көнгәчә дәвам итә. Сабан туеның бер матур күренеше – ахырга калып килгән атка бүләкләрне нәзер әйткән хатын-кызлар да биргәннәр. Шул хакта Гомәр Бәширов менә ничек яза: *«Арттан килгән атның туктый башлавы булды, аны төрле яктан йөгерешеп килгән әбиләр, җиңгиләр сырып алды. Алар кулларындагы ситсыдыр, яулыктыр, тастымалдыр кебек бүләкләрен атның ялына, маңгай чәченә, йөгәненә тагарга*



**Равил Заһидуллин. «Тиздән Сабантуй». «Кырлай турында истәлекләр» сериясеннән. 1987 ел. Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан**

*тотындылар. Тора-бара бүләкләр астыннан атның койрыгы белән колаклары гына күренеп калды. Бәйлиләр, бәйли-бәйли сөйләнәләр:*

*– Улым солдаттан кайтса, – дип нәзер әйткән идем, – ди берсе.*

*– Эчемдәге бүсергә түзәр әмәлләрем калмаган иде. Арттан килгән атка бүләк бирер идек, – дип нәзер әйткәч, Аллага шөкер, әйтмәгәнем генә булсын...*

*Тагын берсе, кызым баладан исән-сау котылса, дип, икенчесе, сыеры тана бозау китерсә, дип адарынган икән».*

Шундый нәзерле бүләкләр тапшыру – Сабан туеның күптәнге традициясе, татар халкының атка – кешенең тугрылыклы дустына ихлас мәхәббәте дәлиле.

**«Аргамак»** һәм **«Сабантуй»** картиналары авторы рәссам **Әлфия Нурхамәтова** нәзер атын сүрәтләгән. Алгы планда – чабыштан кайткан ат, муенында кызыл башлы сөлгеләр һәм яулыклар. Милли бәйрәмебез темасына багышланган икенче эше – **«Сабантуй»** картинасында – Аксубай районы Иске Кыязлы авылындагы Сабантуй бәйрәме.

**Шамил Мотыйгуллинның «Сабантуй моңы»** эшенә күз салыйк. Алгы планда гармунда сыздырып уйнаучы егетне һәм бизәкле аргамакны күрәбез. Картина бәйрәм рухы белән сугарылган.

**Усман Абдуловның «Сабан туе»** (2003) эшендә алгы планда – чәй өстәле, милли ризыклар (чәк-чәк, бавырсак), самавыр. Картинадагы сары төсләр гаммасы бәйрәм рухын күрсәтә. Арткы фонда Казан Кирмәне һәм Кол Шәриф мәчете – узганны һәм киләчәкне берләштерә торган символ булып тора.

**Зөфәр Гимаевның «Батыр»** (2008) һәм **«Бүген бәйрәм»** (2008) әсәрләрендә Сабан туе рухы, миллилек сизелеп тора. Рәссам алгы планга җилкәсенә тәкә салган батырны чыгара. Арткы планда Сабан туе мәйданы. Ә анда уеннар, көрәш гөрләп бара. Рәссамның «Бүген бәйрәм» картинасында авыл өе сурәтләнгән. Биредә – милли ризыклар һәм өстәл түрендә самавыр. Табын артында – баянда уйнаучы түбәтәйле ир-ат. Ак яулыклы алсу күлмәкле яшь хатын – чын татар сылуы. Икенче планда тәрәзәдән бәйрәм күренеп тора. Гимаевның эшләреннән яктылык, нур бөркелеп тора.

Гасырлардан килүче Сабан туе бәйрәме инде ярты гасыр буе сәнгать кешеләрен иҗатка рухландыра һәм киләчәктә дә рухландырачак!

*Рәмзия ГАЙФЕТДИНОВА,*
*фәлсәфә фәннәре кандидаты*

# Татар Сабантуйсыз *булдыра алмый*

(Бәйрәм логотибы турында)

ЕРАК БАБАЛАРЫБЫЗДАН КИЛГӘН МИЛЛИ БӘЙРӘМЕБЕЗ БҮГЕН ДӘ ҮЗЕНЕҢ МИЛЛИЛЕГЕН, АСЫЛЫН ЮГАЛТМЫЙ. БУ ҮЗЕНЧӘЛЕКНЕ САКЛАУДА, ӘЛБӘТТӘ, ХАЛКЫБЫЗНЫҢ – ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕҢ ҺӘМ КИҢ ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕКНЕҢ РОЛЕ ЗУР. Ә ИНДЕ САБАН ТУЕНЫҢ БИЗӘЛЕШЕНӘ, СИМВОЛЛАРЫНА КИЛСӘК, КОЛГА БАШЫНА БӘЙЛӘНГӘН ЯШЬ КИЛЕН СӨЛГЕСЕМЕ, ЯИСӘ ЧАБЫШКЫЛАР МУЕНЫНА БӘЙЛӘНЕЛҮЧЕ ЯУЛЫК ЯКИ КУЛЪЯУЛЫК ДИСЕҢМЕ, ҺӘРБЕРСЕНДӘ ХАЛКЫБЫЗНЫҢ МИЛЛИ БИЗӘКЛӘРЕ ЧАГЫЛА.

2020 елда республика Сабан туеның яңа логотибы[1] булдырылды. Дөресрәге, бәйрәмнең милли бизәкләре дизайн карашыннан чыгып яңартылды, бәйрәмнең төп асылын ачып бирүче макетлар да бастырылды. Логотипның авторы – «Mardesign Заманча этник дизайн студия»се җитәкчесе Айдар Мәрдәншин[2].

Сабан туе – милли мәдәниятебезне яктыртучы маяк ул. Сабан туен – татар халкыннан, татарны Сабан туеннан аерып карап булмый, чөнки Сабан туе дәверләрне тоташтыра, дөньяның төрле почмакларына сибелеп яшәүче татарларны берләштерә, милли тамырларыбызга кайтара. Бу үзенчәлек логотипта «Сабан туе / Безнең бәйрәм» слоганы буларак чагылыш тапкан.

Логотипның төп график билгеләре булып лалә чәчәге, татар читеге, милли көрәшне чагылдыручы ике баһадир (анысы да лалә чәчәге сурәтендә бирелә), Сөембикә манарасы сурәте һәм таҗсыман орнаментлар, түгәрәкләр, пар чынаяк, кашкарый чәчәге тора. Милли бизәкләр, калейдоскоп кебек, республикада уздырыла торган бәйрәмнең төрлелеген, мәгънәсен үз эченә җыйган: татарларга хас кунакчыллык һәм муллык, күмәк уен формалары, халык биюләре, җирлек, ягъни

[1] Логотип – график билге, эмблема яки социумда танылуны һәм тануны арттыру өчен территориаль берәмлекләр, коммерция предприятиеләре, оешмалар һәм шәхси затлар тарафыннан кулланыла торган символ.
[2] Студия современного этнического дизайна Mardesign: СтудияMAR. – Электронный ресурс: mardesign.ru. (Дата обращения 20.12.2020.)





локаль үзенчәлек һәм башкалар. Гомумән, татар орнаментында күп төслелек һәм төрлелек өстенлек итә. Мәсәлән, үсемлек орнаменты сәнгатьнең һәр өлкәсендә дә киң таралыш алган. Аеруча чәчәк мотивларының күплеге, аларны сурәтләүдәге төрлелек һәм элементлар арасында гаҗәеп дәрәҗәдә бай сәнгатьчә бәйләнеш таң калдыра. Чыннан да, лалә чәчәге, таҗсыман орнаментлар, түгәрәкләр, кашкарый чәчәгенең яшел, куе яшел, сары, кызыл яисә куе кызыл төсләрдәге контрасты чәчәк композициясендә уза-




ра гармония тудыра. Шулай ук, Сөембикә манарасы һәм татар читеге сурәтләре дә сары-алтын төсләрдә бирелеп, үзенчәлекле гамма хасил итә. Логотипта кулланылган һәр орнамент, бигрәк тә төсләр гаммасы татар халкына хас тыйнаклык, сабырлык, тырышлык кебек сыйфатларны ача.

Логотипның урта бизәге – лалә чәчәге. Татар сәнгатендә лалә чәчәге – яңарыш символы, орнамент буларак аның белән йортларны, мәчетләрне бизәгәннәр, ул милли кием-салымда еш очрый. Ислам дине кабул ителгәнче лалә чәчәге, күчмә чор элементы буларак, уңышлы нигезләнү, тернәкләнеп китүне белдергән. Бу символ һәр дәвердә үзенең актуальлеген югалтмый, мәсәлән, 1920 елларда ук лалә чәчәкләре







белән бизәлгән читекләр чит илләргә – Франциягә, Германиягә, хәтта Америкага да җибәрелгән. Соңрак, лалә чәчәге Татарстан гербында милләтебезнең, мәдәниятебезнең, республикабызның үсешен күрсәтүче символ буларак үз урынын алды.

Лалә чәчәге кырыенда урнашкан һәр элемент ассиметриядә бирелгән. Кашкарый чәчәге бизәкнең өске өлешендә урын алган. Чәчәк уртасында буш урын түгәрәк, шулай ук татар орнаментының төп график билгеләреннән санала. Логотип үзе дә геометрик фигура формасында ромб рәвешендә ясалган.

Макетларда кулланылган фон, шулай ук, татар сәнгатендәге күптөрлелек белән бәйле. Милли киемнәрдә дә өстенлек күбрәк яшел, сары, шәмәхә, зәңгәр, куе кызыл һәм кызыл төсләргә бирелә. Логотипта кулланылган кара төстәге фон дизайн буларак «Кичке Сабан туе» бәйрәмен уздырганда отышлы. 2020 елда бу макет «Кичке Сабан туе» бәйрәменең, онлайн «Кичке уен»ның логотибы буларак үзен аклады инде[3]. Кара төстәге фон, бер яктан, ул төсләр гаммасын ачса, икенче яктан кайбер төсләрнең камашуын сүлпәнәйтә төшүен ассызыкларга кирәк.

Логотип ул барбөтен символ. Фон һәм орнаментларының төсен урынсыз үзгәртү логотипка салынган төп мәгънәгә зыян да китерергә мөмкин. Төсләрдәге үзара тәңгәллек бу логотипның нигезен тәшкил итә. Орнаментларны кызыл, яшел, куе яшел кебек бер төсләрдә аерым куллану, бигрәк тә футболка, сумка, төрле өс киемнәренә төшергәндә генә үзен аклый, ди белгечләр. Димәк, логотипны кулланабыз икән, аны дөрес һәм урынлы итеп куллана белү дә бик мөһим.




«Бу логотипны бренд дәрәҗәсенә үстерү өчен бөтен алшартлар да бар. Мәскәү, Казан, Европада үткәрелүче Сабан туеның логотибын ясау тәҗрибәсен истә тотып, мин курыкмыйча әйтә алам, бу логотип Казан Сабан туеның бренды булырга тиеш. Бу логотипны куллану, киемнәргә төшерү, төрле форматларга күчерү бик җиңел», – ди логотип авторы Айдар Мәрдәншин.

Дөрестән дә, бу бәйрәм бөтен татарныкы, әмма аны безнең җирлектән, Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәреннән аерып карап булмый.

[3] Сабан туе 2020. – Электронный ресурс: https://www.youtube.com/playlist?list=PLI1AP6vXY23qwkuVGwZW5VvyLe9x9DSs. (Дата обращения 19.12.2020)

*Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА,*
*композитор, фәлсәфә фәннәре кандидаты*

# САГЫНМАК ДИП БӘЕТ ЯЗДЫМ...

**Безнең татар-башкорт халкы тарихи, шәхсән фаҗигале вакыйгаларны поэтик рәвештә беренче заттан хикәяләнгән әсәрләргә бәет исемен биргән. Бәет – фарсы, гарәп һәм төрки шигърриятенең минималь строфа берәмлеген аңлатса, без бәетне халкыбызның югары хиссият киеренкелеген тәшкил иткән жанр итеп таныйбыз. «Чү, әз генә бернәрсә шылт иттеме, хәзер бәет чыгарыла» ди, Габдулла Тукай, жанрны күз алдында тотып. «Сагынмак дип бәет яздым, газиз иркәм, сезгә» ди, Габделҗаббар Кандалый поэтик калыпка ымлап.**

Бәетләрне сүзне моңга төреп, хәсрәт кичергән кешеләр иҗат итә. Бәет язу сәнгатендә һәр сүз әһәмияткә ия, чөнки ул күңел халәтенең иң ящерен нечкә кылларына кагыла. Көнчыгыш шигырь язу кануннарыннан азат ителгән, халыкның милли зәвыгына бәйләнгән, саф татар телендә иҗат ителеп дәфтәрләргә теркәлеп, кулдан кулга йөргән бәет жанрын татар-башкорт халкының профессиональ язма әдәбиятына кертеп була. Сүзләремне дәлилләргә профессиональ бәетче Фәизә апа Сәгыйтованың (Уральск, Казахстан) сүзләрен китерәм: «Берсе кичергән, берсе язган, берсе күчергән, һәм ул гыйбрәткә ия».

Үткән гасырның азаккы елларында без, Казан консерваториясенең бер төркем студентлары һәм мин, аларның җитәкчесе, Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы авылына халык авыз иҗаты җыярга килдек. Колхоз җитәкчесе Мөхтәр әфәнде безнең Казаннан килүебезне белгәч: «Уборкага килгән механизаторларны тәрбияләгән кебек ризык белән тәэмин итегез», – дигән боерык бирде. Анда тупланган материалларны файдаланып чыгарылыш дипломнары язылды, докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре якланды. Татар Каргалысы экспедициясендә катнашкан студентлар хәзерге көндә чит илләрдә (Бельгия, Германия), Казан, Мәскәү, Петербургның фәнни фольклор белән бәйле учреждениеләрендә уңышлы хезмәт итә.

Татар Каргалысында һәр гаиләдә диярлек борынгыдан калган, кадерле мирас итеп сакланган бәетләр дәфтәре бар. Халкыбызда таралган «Манара бәете»н күз яшьләренә коенып, Татар Каргалысында иҗат иткәннәр: «1928-1929 елларда мәчетләрне сүттеләр. Каргалының ун мәчетеннән бер мәчет калды. Мәчетләрне сүткәндә Каргалыда җыелышып язганнар ул бәетне».

Фатыйма апа Галиулла кызы Абдрахманова дәфтәреннән:

*«Хәмидәбануның туенда ала*
*чучканы суйдылар,*
*Чучка итен ашамагач,*
*муенына пычаклар куйдылар.*
*Чиркәү баскычын менгәндә*
*уң аякларым тала ла,*
*Талганына үкенмимен,*
*ислам динем жәл кала».*

Улы фаҗигале рәвештә вафат булган Мәдинә апа Мөрсәлимова (1928 елгы) да бәет язган:

*«Чегәннәр туп атадыр,*
*төтене ергә ятадыр,*
*Балакаем, бахыркаем,*
*җир куенында ятадыр».*

Мин әле дә Татар Каргалысы кешеләре белән элемтәдә торам. Китапханә мөдире Зөлфия Усманова-Мөлекова миңа һәрвакыт ярдәмгә килә. Кайбер студентларыбызның татарча белеп җиткермәве аркасында мәгълүмат дөрес күрсәтелмәгән. Зөлфия шуларны ачыклый, аның ярдәме әйтеп бетергесез кыйммәтле. Ул үзе бик талантлы: русча да, татарча да шигырьләр яза.

Фамилиясе Мөлекова булгач, сорашкан идем: композиторыбыз Бату Мөлековның кодачасы булып чыкты. «Әтием әйтә иде, Бату абый белән балыкка йөридер идем дип. Тик Бату абый белән сөйләшеп булмыйдыр иде. Сөйләшә генә башласаң, сызгырып матур көйләрне көйли иде дип».

Дөньялар, кызганычка каршы, ал да гөл түгел. Берничә ел элек Татар Каргалысында үзәк өзгеч фаҗига тирә-якны тетрәндерә. Шул вакыйганы тасвирлап Зөлфия бәет яза.

# Зөлфия УСМАНОВА (МӨЛЕКОВА):



*«Кечкенәдән ишетә беләм бәетләр турында. Берәр матур көйгә кызганыч эчтәлекле сүзләрне моңлы итеп әтием җырлый торган иде. 2011 елда, Ходай рәхмәте булгандыр инде, мин шигырьләр яза башладым. 2015 елда үзем бәет язарга булдым. Бәет язуы җиңелдән булмады, чөнки бик кызганыч, куркыныч хәлләрне яңадан үзем аша үткәрергә туры килде.*

*Минем сугышта үлеп калган Закир бабаем белән Мәфтүхә әбиемнең ике улы – Шакир белән Зариф булган. Мин Зарифның төпчек кызы Зөлфия булам, зур кызы Әлфия апай. Шакир абыйның өч баласы – кызы Фирая, уллары Зөфәр белән Җәлил.*

*Мин кечкенәдән нишләптер шул Җәлил абыемны ярата идем. Ул да мине уйнатырга, очындырырга тырыша иде. Ул Гөлгенә җиңгигә өйләнгәч тә, мин гел аларга килеп йөри торган булдым. Алар да мине ак йөзләрен күрсәтеп каршы ала иде. Алы-артлы аларның ике балалары булды – кызлары Гүзәл һәм уллары Марат. Бик матур гаилә иде. Җәлил абыемны яратканга мы мин бу балаларны да бик нык яраттым. Ишектән килеп керүемә бер дә ятсынмыйча икәүләшеп алдыма менеп утыралар иде. Шундый сөйкемле иде Гүзәл сеңлем һәм төпчек булуына карамастан Марат энем җитез иде. Матур акыллы балалар булып үсеп киләләр иде.*

*Мәктәпне тәмамлап, 1990 елны мәдәният укуханәсенә укырга кердем. Өченче курста укыганда, 1993 елның гыйнвар аенда практика үтәргә Переволоцки районының Степановка авылына юл тоттым. Мәдәният йортында эшли башладым. Кулга аккордеонны тотып, «Ягодка» балалар фольклор ансамбле оештырып, аның җитәкчесе булдым. Янымда иптәш кызларым да булды, алар да минем белән бергә практика үтәргә килгән иде. Февраль аеның бер төнендә: «Гөлгенә, Гөлгенә», – дип кычкырып саташып уяндым. Төшемдә бер хатын ике баласын ике кулына тотып күмер сараена кергән дип күрдем. Хатынны танымадым, ләкин нишләптер, эчем пошып аңа: «Чыгыгыз аннан!» – дип кычкырдым. Икенче көнне иртүк мәдәният мөдиреннән өемә кайтырга рөхсәт алмакчы булдым, ләкин ул мине җибәрмәде: «Бүген эшләрең күп, бар, эшлә, ә иртәгә иртүк юлга чыгарсың!» – диде. Икенче көнне иртүк автобуска утырып Переволоцкидан Оренбург вокза-*

*лына кайтып төштем. Каргалыга билет алып, авылдашым Хафиза апай янына барып утырдым. «Хәлләр ничек, Хафиза апай? Авылда нинди хәбәрләр бар?» – дип сорадым. Ул авылдагы хәбәрләрне сөйләргә тотынды һәм бик кызганыч, бик куркыныч бер хәбәрне сөйләп куйды. «Авылда мәктәптән ерак түгел бер өйдә ут чыкты һәм өйдә булган ике бәләкәй бала төтен исенә буылып үлде», – диде. Мин инде: «И Ходаем, кем балалары инде алар?» – дип сорадым. Ул «Җәлил белән Гөлгенәнең балалары», – дип әйтте. Әйтүе дә булды, минем йөзем үзгәргәнен күреп, гафу үтенә башлады: «И Зөлфия сеңлем, сез туганнар икәнен онытканмын бит…» – диде. Минем колагым томаланды һәм тын җитешмәгән кебек булды. Автобуска кереп утырдым һәм өйгә кайтып җиткәнче беркем белән дә сөйләшмәдем, еламадым да, шок булгандыр дип уйлыйм. Өйгә кайтып та кердем, бусагага утыруым да булды, эчемдә булган бөтен әчелекне, авырлыкны чыгарып, кычкырып елап җибәрдем. Үксеп елаганымны ишетеп яныма әнием чыкты, аның беренче сүзе: «Кайттыңмени, кызым?» – булмады, «Кем әйтте, балакаем?» – диде. Азрак тынычлангач, әнием: «Җәлил абыең сиңа телеграмма сугарга кушмады. «Балаларны нык ярата иде, йөрәге күтәрмәс», – диде. Шуңа күрә әнием язмаган. Иртәгә өчесе була дигән көнне кайттым. Бер көн алдан кайткан булсам, балаларны азаккы юлларына озаткан булыр идем. Бик үкенәм шуңа әле бүген дә. Мәрхүмә Гүзәл белән мәрхүм Маратның әрвахлары шат булсын, тыныч ятсыннар сабыйлар. Ходай беребезгә дә күрсәтмәсен андый әче бала кайгысын! Аллам сакласын! Исән-сау гына яшик! Барыбызга да шуны телим, амин!»*

# БӘЕТ

***(Мәрхүмә Гүзәл (5 яшь) һәм мәрхүм Маратка (4 яшь) багышлана)***

*Бик яшь килеш мин бит киттем, мин бит киттем авылымнан,
Ерактагы бер авылга, гамәлләрне башкарырга.
Кышкы суык бураннарда килеп җиттем бу авылга,
Дус кызларым каршы алды, туган авылым ерак калды.
Хәзер инде эштә көндә, мәдәният йортларында,
Эш җиңелдән дә бит түгел, балаларга ачам күңел.
Эшләгәнгә үтте бер ай, бар эшләрем бара бит җай.
Тик бер төнне бик саташтым, һәм кычкырып мин уяндым.
Төшләремә керде таңда бер ир бала һәм кыз бала,
Әнкәйләре белән алар йөгереп керделәр сарайга.
Ул сарай бик нык караңгы, сарай тулы күмер ташы.
Мин кычкырдым: «Әй, Гөлгенә! Чык син аннан,чык тиз генә!»
Мин кычкырдым әнкәсенә, мин кычкырдым: «Чык тиз», – диеп,
«Пычраналар балаларың, чыгар аннан сабыйларың».*

*Ишетмәде әнкәләре, кычкырганны ачы итеп,*
*Үз тавышыма уяндым, уяндылар дус кызларым.*
*«Ник кычкырасың син?» – диеп, сорадылар миннән кызлар,*
*Өйдә кайгы булды микән, ник мондый төш күрдем икән?*
*Иртән барып мин үтендем мәдәният мөдиреннән,*
*«Кайтыйм әле,кайтыйм өйгә, кайтыйм әле, мин бер көнгә».*
*«Бүген синең эшләрең күп», – диеп әйтте мөдир миңа,*
*«Иртәгәдән соң кайтырсың, нигә болай ашыгасың?»*
*«Йөрәгемдә тыныч түгел, шуңа күрә мине кайтар,*
*Бер көнгә, һич бер бит көнгә, күңелемне тынычландыр».*
*Кайтармады, ләкин мөдир, «Эшлә! – диде. – Син эшеңне,*
*Иртәгедән соң кайтырсың, нигә болай ашыгасың?»*
*Үтеп китте озын төнем, килеп җитте кайтыр көнем,*
*Кайтып җиттем тиздән генә мин Оренбург вокзалына.*
*Билет алып мин утырдым, бер танышымның янына,*
*«Ни хәлең бар?» – дип сорадым, «Ни хәлләр бар авылымда?»*
*Ул сөйләде тотып кулны булган бер куркыныч хәлне.*
*«Кайгы булды бик кызганыч, ишетмәгәнсеңдер инде.*
*Менә безнең Каргалыда, өйгә ут кабындырганнар,*
*Өйдә булган ике бала, шул исенә буылганнар.*
*Әзерләдек ике табут ике сабый балаларга,*
*Кара кайгы төште анда безнең татар авылыбызга.*
*Мин сорадым: «Кемнәр?» – диеп, «Мондый кайгы күргән?» – диеп,*
*Бик кызгандым мин аларны, язмыш биргән бит кайгыны.*
*Авылдашым миңа әйтте, шул сабыйлар исемнәрен,*
*Шуннан күреп минем йөзне ул аңлады, ни әйткәнен.*
*«И, Ходаем,онытканным туганнарың икәнлеген,*
*Гафу ит син, мөмкин булса, бу кайгыга, түзә алсаң».*
*Мин шаккаттым бу хәбәрдән, абый балаларын беләм,*
*Ике бала, кан туганым, нигә болай булды, Раббым?*
*Кайтып җиттем авылыма, йөрәгемне кайгы какты,*
*Һәм утырып бусагага күзләремнән яшьләр акты.*
*Елаганымны ишетеп, яннарыма әнкәм чыкты,*
*«Балакаем, – диде миңа. – Кемнәр әйтте, моны сиңа?»*
*«Хат язма, – дип, әйтте абыең, – йөрәккәе түзмәс аның,*
*Балаларны бик яратты… Хат язмадым тыңлап аны».*
*Озата да бит алмадым, иң азаккы юлларына.*
*Һич түзәлмыйм, бик нык ярсыйм бу кайгының хәсрәтеннән.*
*Гүзәл белән Мараткаем, мәрхүм сабый балаларым,*
*Сез гел минем йөрәгемдә, багышладым бәет сезгә.*
*Бар кешенең күңелендә шушы бәет яңгырасын,*
*Һичкемгә дә мондый хәсрәт язмыш башка күрсәтмәсен.*

*Филүзә МӘРДАНОВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең матди булмаган мәдәни мирас бүлеге мөдире*

# ТАТАР булмый комгансыз

*Өй күтәрдек өмә белән,*
*Нигез тулы тәңкәләр.*
*Өй котларга килдек без дә,*
*Кулга тотып бүләкләр.*
*Ушаны куйдык беркетеп,*
*Комган шунда куярсыз.*
*Алып килдек без аны да,*
*Татар булмый комгансыз.*

***(Минзәлә якларында өй котларга килгәндә җырлый торган җыр)***



**Тутыкмас корычтан һәм бакырдан ясалган комганнар. Фоторәсем Илдар Солтановның шәхси архивыннан**

ТАТАРНЫҢ ИҢ БОРЫНГЫ ДЕКОРАТИВ ИҖАТ ТӨРЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕ БУЛЫП, МЕТАЛЛНЫ СӘНГАТИ ЭШКӘРТҮ ТОРА. АРХЕОЛОГИК ЭЗЛӘНҮЛӘРДӘН КҮРЕНГӘНЧӘ, ӘЛЕГЕ БОЛГАР-ТАТАР ҺӨНӘРЕ VIII-XVI ГАСЫРЛАРГА БАРЫП ТОТАША. МЕТАЛЛНЫ НӘКЫШЬЛӘҮ АЛЫМНАРЫ БИЗӘНҮ ӘЙБЕРЛӘРЕНДӘ, КӨНКҮРЕШ ҖИҺАЗЛАРДА, КОРАЛ ЯСАУДА, АТ ҖИГҮ КИРӘК-ЯРАГЫНДА КУЛЛАНЫЛА[1].



**XV-XVI гасырларда Казан ханы Мөхәммәтәминнең сарай остасы Насыйр тарафыннан ясалган җиз шәраб чүлмәге. Татарстан Республикасы Милли музееннан**

XVI гасыр уртасыннан татарларда металлны нәфис эшкәртү аерым төр эшләнмәләр җитештерүгә тыюлар белән регламентлана. Казанны яулап алганнан соң, күп санлы баш күтәрүләр башлана. Аларда рус булмаган халыклар актив катнаша. Баш күтәрүчеләргә корал әзерли алмасыннар өчен җирле халыкка тимерчелек эше белән шөгыльләнү тыела. Татар авылларында крестьян хуҗалыгы өчен кирәк-яракны рус тимерчеләре ясый. Әлеге тыюлар XIX гасырда гына үз көчен югалта. Әмма бу вакытта җирле халыкта, шул исәптән татарларда да, тимерчеләр калмый. Шулай итеп, тамырлары болгарларга барып тоташкан тимер эшкәртү традициясе өзелә[2].



**1890 елгы комган. Казан губернасы Мамадыш өязенең Кукмара бистәсендә сәүдәгәр Н.Д. Володин остаханәсендә ясалган. Кукмараның Туган якны өйрәнү музееннан**

[1] Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е – начало 1990-х годов). – Казань: Фән, 1995. – С. 140.
[2] Воробьев Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и в настоящем. – Казань, 1957. – С. 29.

Җирле халыкка тимердән кайбер көнкүреш әйберләрен генә җитештерергә рөхсәт ителә. Болар – комганнар, су савытлары, табаклар һәм башкалар. Иң киң таралганы металлдан чүкеп ясалган комган була.

Татар комганының төп үзенчәлеге – аның борынын кош яки хайван башына охшатып эшләү. Бу үзенә күрә бер саклагыч бөти ролен дә уйный[3]. Металл эшләнмәләрне болай бизәү – болгар декоратив сәнгатенең эчтәлеген һәм стилен ачып бирә – биредә күпмедер күләмдә образлы фикерләүнең мифологик системасы чагылыш таба. Алга таба бу ислам кануннары белән чикләнә һәм металл әйберләрдә төрле декоратив бизәкләр өстенлек ала[4]. Еш кына комганга намаз уку вакытларын һәм тәсбихне символлаштыручы бизәкләр төшерелә. Комганның капкачы ай куелган мәчет манарасы рәвешендә ясала. Гадәттә татар комганының борынында бөҗрасы була. Мондый төр комганнарны «сөннәтле комган» дип тә атыйлар.

XV-XVI гасыр бакыр эшләнмәләренең уникаль үрнәге булып, Татарстан Республикасының Милли музеенда саклнучы тар муенлы, тоткалы чүлмәк санала. Нәзакәтле итеп, бизәп ясалган әлеге җиз шәраб чүлмәге якынча XV-XVI гасырларда Казан ханы Мөхәммәтәминнең сарай остасы Насыйр тарафыннан ясалганлыгы билгеле[5].

XIX-XX гасырларда комган күпчелек көнкүрештә кулланыла, шуңа да бизәксез генә ясала. Комган ясау белән татар авылларында яшәүче бакырчылар шөгыльләнә[6]. Нигездә тәбәнәк кенә бакыр һәм җиз комганнар ясыйлар. Шунысы игътибарга лаек, мондый формалы комган тәһарәт алганда суны чамалап тотарга мөмкинлек бирә. Савытның һәр детале уйланылган: муены нечкә, су түгелмәсен өчен борыны тар һәм озын. Киң төбе тотрыклылык бирә, комган аумый. Ә капкачы, өлкән яшьтәге кеше торганда, таянырлык итеп эшләнә.

Болардан тыш мәет юа торган махсус комганнар да була. Бу максатларда кулланыла торган суның күләме алдан билгеләнә һәм ул, кагыйдә буларак, комган саны белән үлчәнә. Җиде комган – ритуаль суның шартлы, сакраль үлчәме. Гәүдәнең физик торышына карап, мәетне юу өчен тугыз, кайчагында унбер комган су кулланыла[7].

XIX гасырда комган ясау үзәге булып, Казан һәм Казан губернасының Тәтеш, Чистай, Лаеш өязе авыллары санала. Лаеш өязенең Югары Ачы авылында, мәсәлән, 55 хуҗалыкта комган ясыйлар. Җитештерү масштабы үсә бара: XIX-XX гасыр чигендә комган ясаучылар саны 80 нән 180 кешегә кадәр җитә[8]. 1917 елга кадәр мондый савыт-саба Вятка губернасының Малмыж өязенә кергән Күкшел, Мәмәшир, Уразай, Янсыбы авылларында җитештерелә[9]. Нижгар, Саратов губерналарында да комган ясау белән шөгыльләнүчеләр була.

Казан губернасында иң зур металл эшләнмәләр җитештерү үзәкләренең берсе – сәүдәгәр Н.Д. Володинның Мамадыш өязенең Кукмара бистәсендә урнашкан шәхси предприятиесе. Кукмарада бакыр һәм җиз комганнар, самавырлар, савыт-саба һәм хуҗалык кирәк-ярагы җитештерү эше 1865 елдан башлана. Металл эшләнмәләр ясау эшенә 1851 елгы зур янгыннан соң ябылган Кукмара бакыр эретү заводыннан калган осталар җәлеп ителә.

Володин маркасы белән җитештерелгән металл эшләнмәләрнең ассортименты турында өлешчә мәгълүматны 1890 елгы Казан фәнни-җитештерү күргәзмәсе катало-

[3] Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.У. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. – М.: Советский художник, 1990. – С. 14.
[4] Шунда ук. – 15 Б.
[5] Шунда ук. – 16 Б.
[6] Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е – начало 1990-х годов). – Казань: Фән, 1995. – С. 140
[7] Брусько З.М., Завгарова Ф.Х. В круге жизни. – Казань: Ихлас, 2013. – С. 123.
[8] Кустарная промышленность России. Разные промыслы. – СПб, 1913. – Т. II. – С. 364; Текущая статистика кустарных промыслов // Отчеты и исследования по кустарной промышленности России. – СПб, 1898. – Т. 5. – С. 370.
[9] Халиков Н.А. Промыслы и ремесла татар Поволжья и Урала (середина XIX – начало XX в.). – Казань: Мастер Лайн, 1998. – С. 64



**Комган ясаучы оста Илдар Мөхәммәтхан улы Солтанов, Татарстан Республикасының Балтач районы Кече Лыза авылы**

гыннан алырга була[10]. Анда 6 төрле комган (кургаш йөгертелгән, яшел бакырдан, томпактан ясалган юл комганы, азия комганы һәм кырлы комган), алар белән бер комплектта булган тазлар, мәчетләр өчен ритуаль савыт-саба, шулай ук 3 төрле самавыр кертелә.

Сәүдәгәр Н.Д. Володинның бакыр әйберләр остаханәсендә 15 оста хезмәт куя. Остаханә ел әйләнәсе эшли. Аның продукциясе, кыйммәт булуына карамастан, тирә-якта да, чит илләрдә дә танылa. XIX гасыр ахырында комганның бәясе 2 сумнан башлап, 3 сум 50 тиенгә кадәр җитә. Әзер товар Мәкәрҗә һәм Минзәлә ярминкәләрендә сатыла[11]. Кукмара осталарының эшләре Париж, Чикаго[12] күргәзмәләрендә тәкъдим ителә. Хәзер алар Кукмара туган якны өйрәнү музееның фондларын бизи. Биредә «В Кукморе. Александр Володин», «В Кукморе. Братья Володины» (1890) дип чүкеп язылган комганнар саклана.

Тора-бара Кукмарада бакыр эшенә игътибар кими һәм ул әкренләп юкка чыга. Беренчедән, бу 1917 елгы революциядән соң булган предприятиеләрне хуҗаларыннан тартып алу белән бәйле. Икенчедән, бакырчылыкны тимерчелек кысрыклап чыгара. Революциягә кадәр үк тимерчеләргә ихтыяҗ зур була. Көнкүрешнең төрле тармакларында тимердән ясалган әйберләр күбрәк кулланыла башлый[13].

Татар авылларында сирәк булса да әле дә бакырчыларны очратырга мөмкин. Татарстанның Балтач районы Кече Лыза авылыннан Илдар Мөхәммәтхан улы Солтанов шундыйлардан – ул самавырлар һәм комганнар эшли. «Берәү миннән җиз комган табып бирүемне сорамаса, бәлки, мин бу эшкә тотынмаган да булыр идем. Мин ул вакытта төсле металл җыю белән шөгыльләнә идем», – дип искә ала оста. Илдар Солтановка бу һөнәр кызык булып тоела. Җиз комганнар ясарга аны күрше Балтач авылында яшәүче, комган ясау остасы Габделфәт ага өйрәтә. Соңрак Илдар Солтанов тутыкмый торган корычтан ялтыравык комганнар ясый башлый. Бу – катлаулы хезмәт, чөнки мондый комганның детальләрен махсус технология буенча тоташтырырга кирәк. Илдар Солтанов үзе ясаган металл эшләнмәләрен төрле күргәзмәләргә куя, ярминкәләргә алып чыга.


Күргәнебезчә, озак вакытлар комган татар йортының бик кирәкле бер җиһазы була, өйдә тукылган сөлге, җиз ләгән белән бергә этник һәм дини символ булып санала. Кызганыч, хәзер кулдан ясалган комганнарга ихтыяҗ бетеп бара, чөнки кибет киштәләрендә пластмасс комганның күптөрле вариантлары тәкъдим ителә.

[10] Каталог Казанской научно-промышленной выставки 1890 г., состоящей под покровительством его императорского высочества государя наследника цесаревича / Н.А. Осокин. – 2-е издание значительно дополненное. – Казань : Типография Н. А. Ильяшенко, 1890. – 121 с.
[11] Шунда ук.
[12] Кустарная промышленность России. Разные промыслы. – СПб, 1913. – Т. II. – С. 365.
[13] Валиев Ф.Х. История Кукмора. Медные заводы. – Казань: «Идел-Пресс», 2013. – С. 154.

*Евгения ШЕМЕЛОВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге методисты*

# ПИТРӘЧ *керамикасы* *һәм* ПИТРӘЧ *тәрбиясе*

НӘФИС КЕРАМИКА СӘНГАТЕ – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ИҢ БОРЫНГЫ ДЕКОРАТИВ ИҖАТ ТӨРЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕ. ПИТРӘЧ РАЙОНЫ БУ ГАМӘЛИ СӘНГАТЬ ТӨРЕ БУЕНЧА ТАТАРСТАН БРЕНДЫ БУЛЫП САНАЛА. ПИТРӘЧ ЧҮЛМӘК ҖИТЕШТЕРҮ КӘСЕБЕ РУС ТРАДИЦИОН ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕ БАЗАСЫНДА БАРЛЫККА КИЛӘ, ӘММА АНЫҢ УНИКАЛЬЛЕГЕ КАЗАН ТАТАРЛАРЫ МӘДӘНИЯТЕ ТАРИХЫНА ТАБИГЫЙ ЯРАША АЛУЫНДА.



**XX гасыр башында Питрәч осталары эше**

Питрәч халкы балчыктан савыт-саба әвәләп ясау кәсебенә XIX гасырның беренче яртысында керешә. Бәя күтәрү өчен кайбер крестьяннар савыт-сабага бизәк тә төшерәләр. Аларга Казан Сынлы сәнгать училищесы педагоглары ярдәмгә килә. Казанда 1890 елгы фәнни-җитештерү күргәзмәсенә әзерләнгәндә әлеге кәсеп белән Казан өязе земствосы кызыксына – камилләштерелгән мичләр ясарга һәм гомумән яңа җиһазларга акча бирә. XX гасыр башында керамикага укыту остаханәләре нәкъ менә Питрәчтә барлыкка килә. Остаханәләрне үзенең рәссам хатыны белән бергә инженер-технолог Александр Ильинский җитәкли. Алар икесе дә Петербургның Штиглиц училищесын тәмамлый. Ильинскийлар җитештерүне югары дәрәҗәгә күтәрә: Питрәч осталарының эшләре кыска гына вакыт эчендә бөтен Россиягә танылып дан казана. 1915 елда Питрәч керамикасы Париж күргәзмәсендә призлы урын яулый. Шулай итеп, XIX гасыр азагы – XX гасыр башларында Питрәч үзенчәлекле оригиналь сурәтләү традициясе булган сәнгать үзәгенә әверелә. Беренче тапкыр балчык савытка

татар бизәге төшергәннән соң, Питрәч керамикасы аеруча танылa. Питрәч осталарының эшләре Дәүләт Эрмитажы, Россия этнография музее, Татарстан Республикасы Милли музее, Казан федераль университетының Археология музее фондларында, Питрәч авылы туган якны өйрәнү музеенда саклана. Әмма XX гасырда әлеге кәсепчелек сүнеп кала.

Питрәч районында керамик савыт-саба ясау һөнәрен яңарту эшенә Наталья Пилюгина алына. Ул – ТРның Рәссамнар берлеге һәм ТРның Һөнәрчеләр палатасы әгъзасы, халык һөнәрчелеге остасы, «Яратам Казан» керамика гаилә остаханәсе җитәкчесе.

Питрәч керамикасы коллекциясен Наталья Анатольевна архив чыганакларын өйрәнеп, музей фондларында сакланган эшләнмәләр нигезендә иҗат итә. Алга таба каталог булдыру планлаштырыла.

«Минем өчен иң мөһиме – коллекцияләрне торгызу гына түгел, әлеге һөнәрне саклау, үстерү һәм яшь буынга шушы белемне тапшыру», – ди Наталья Пилюгина.

2020 елда Наталья Анатольевна «XIX-XX гасырда үзенең традицион урынында Питрәч керамикасы яңарышы» проектын әзерли. Татарстан Республикасыннан халык һөнәрчелеге буенча бердәнбер булган бу проект быел Президент грантлары фонды конкурсында җиңеп чыкты. Проектның төп максаты – тормыш авырлыгына юлыккан балаларга социаль ярдәм, профориентация, республикада традицияләрне саклау.

2021 елның февраленнән башлап, Питрәчнең «Шатлык» балалар һәм үсмерләр социаль приютында балчыктан әвәләп савыт-саба ясау дәресләре оештырыла башлый – биредә тәрбияләнүче 5-15 яшьлек 24 бала һөнәргә өйрәнә. Балаларга татар орнаментлары да өйрәтелә, чөнки алар балчык әйберләр бизәгендә аеруча кирәк. Балалар ясаган савыт-сабаны Наталья Анатольевна үз остаханәсендә яндыра, чөнки яндырып эшләү балалар өчен куркыныч.

Приютта балчык әйберләрнең зур булмаган күргәзмәсе барлыкка килгән. Приют педагоглары һәм тәрбиячеләре әйтүенчә, балчык белән эшләү балаларны тынычландыра, аларда курку, шомлану хисләрен һәм агрессияне киметә, гиперактив һәм йомык балалар өчен психотерапевтик ярдәм күрсәтә; үзара аңлашырга һәм коллективта эшләргә өйрәтә.

«Быелның май-июль айларында тәрбияләнүчеләрнең эшләре «Туган авылым» мәйданчыгында, Питрәч районы чараларында тәкъдим ителәчәк, – ди Наталья Пилюгина. – Бу Татарстанда халык һөнәрчелеген саклау буенча зур проектның башы гына. Без үзебез тәрбияләгән балаларны алга таба да күзәтеп торачакбыз, аларның бер өлеше булса да, керамика белән кызыксынырга мөмкин. Бәлки, Питрәчкә әйләнеп кайтып, ата-баба һөнәрен дәвам итәрләр».



**Наталья Пилюгина ире Рафис Сәмигуллин белән**



**Н. Пилюгина иҗат иткән Питрәч керамикасы үрнәкләре**

Фоторәсемнәр Н. Пилюгинаның шәхси архивыннан һәм Питрәчнең туган якны өйрәнү музееннан

*Динара ФӘРДИЕВА,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге фәнни хезмәткәре*

# ИКМӘК *салу серләре*



ЭЛЕК-ЭЛЕКТӘН ТАТАРЛАР РАЦИОНЫНДА ИПИ ТӨП ҺӘМ ИЗГЕ РИЗЫКЛАРНЫҢ БЕРСЕ БУЛГАН. ИДӘНГӘ ИКМӘК ЫРГЫТУ, ИПИ ВАЛЧЫКЛАРЫН ТАПТАУ КАТГЫЙ ТЫЕЛГАН, ИКМӘКТӘН БИЕГРӘК УТЫРУ ДА ХӨРМӘТСЕЗЛЕК БИЛГЕСЕ САНАЛГАН. ЭЛЕК «ИПИДЕР» ДИП АНТ ИТҮ ГАДӘТЕ ДӘ БУЛГАН. ЖУРНАЛИСТ ҺӘМ ПЕДАГОГ ӘХМӘДҺАДИ МАКСУДИНЫҢ XX ГАСЫР БАШЫНДА БАСТЫРЫЛГАН «ГЫЙБАДӘТЕ ИСЛАМИЯ» КИТАБЫНДА ИКМӘККӘ КАГЫЛЫШЛЫ КИҢӘШЛӘР БАР: «ИПИГӘ ПЫЧАК КУЯРГА КАТГЫЙ ТЫЕЛА; ПЫЧАКНЫ ИКМӘККӘ СӨРТМӘГЕЗ» ҺӘМ БАШКАЛАР.

Элекке вакытларда гаиләдә икмәк пешерү бик җаваплы эшләрнең берсе саналган. Биредә каенана йортына төшкән киленнең бу эштә уңганлыгы да сыналган. Шул ук вакытта каенана киленгә үзенең барлык белемен һәм тәҗрибәсен бирергә, тәмле итеп икмәк пешерергә өйрәтергә омтылган, шулай итеп, бик борынгы һәм кызыклы серләре буыннан-буынга күчеп килгән.

Фәнни-популяр китапларда, нигездә, ипи пешерү рецептурасы бирелә. Мәсәлән, ипи пешерү рецептлары Ю. Әхмәтҗановның «Татар халык ашлары һәм «Икмәк кадере» китапларында җентекләп язылган. И. Юшков, 1861 елда Тубыл губерниясе Тубыл һәм Тара округы татарларының туклану культурасын өйрәнеп, икмәкнең ике төрле пешерелүен искәртә: ачыткысыз арыш ипие (арышитмак) һәм ак ипи (нан).

Матур әдәбият әсәрләрендә ипи пешерү темасына зур игътибар бирелә. Мәсәлән: М. Мәһдиевнең «Бәхилләшү» повесте, Ф. Салихның «Әни ипи сала» хикәясе һәм башкалар. «Ипи салу... Дөньяда иң игелекле, мәгънәле, иҗади бер эш ул. Ипи салу – хатын-кызның бер тәүлеккә сузылган эше. Бу тәүлектә йортта зур, тыныч шатлык, тынлык, тантана. Ипи салган тәүлектә ир белән хатын арасында ызгыш-талаш булмый. Ыбыр-чыбырлы бала-чага да бу тәүлектә тынып тора... Ипи салу... Ул – ничек? Аңаниләр кирәк? Кирәк әйбер күп түгел. Иң беренче – эш ярата торган, бай күңелле хатын кирәк. Аннан кала, яккан утыныңнан тиешле эсселек тудыра алырлык уңышлы, игелекле мич кирәк. Әлбәттә, коры утын кирәк. Кара чыршы, каен, имән утыны. Калганнары – зирек, юкә, ак чыршы, нарат – ярамый. Ләкин аларның да үз урыны бар: әйтик, коймак, кабартма пешергәндә, юкәсе төшерелгән сөян – Казан артында «сөям» – кирәк. Тагын ниләр? Күәс чиләге».

Элек, чүпрә булмаган заманнарда, икмәк камырын колмак ачыткысы белән куя торган булганнар. Зәй районының Имәнлебаш авылында ипине һаман да колмак белән пешерәләр. Әлеге авылда яшәүче Бибисәйдә Хөснетдинова болай сөйли: «Иң элек ачыткы ясарга кирәк. Бер литр суга бер уч кипкән колмак салам да кайнатырга куям. Су сары төскә кергәнче кайнатам. Аннары бер касә коры онга шул дөбердәп кайнап чыккан суны салып, боламык ясыйм. Аннары җылы урынга куеп, 24 сәгать буе ачытам. Менә шул чүпрә урынына куллана торган ачыткы була да инде. Әзер ачыткыны суыткычта саклыйм, берничә тапкыр ипи пешерергә җитә ул. Әйтик, миңа өч ипи пешерергә кирәк икән, бер аш кашыгы колмак ачыткысы белән камыр изеп куям. Кичтән изәм – иртән камырны басам. Камыр кабаргач, калай табага салам. Җитлеккән камыр, табага салгач, яргаланып китәргә тиеш – кабарып җиткәнен шуннан беләсең. Ипи пешеп чыккач, тастымалга төрәм дә мендәргә каплап салам. Беренчедән, бу – ипине хөрмәтләү. Икенчедән, кызу утта пешкәч, ипи катып китә, ә тастымал белән төреп, мендәргә каплап салсаң, йомшый, тәм керә. Әнкәйләр «ипине салкын тешләмәсен» дип сөйләшә торган иде. Колмак ипие җылы ярата. Әнкәйләр әйтмешли, «салкын тешләсә» – уңмый».

Ипинең тәме, сыйфаты пешерүченең оста кулыннан да тора. Арча районының Сеҗе авылында яшәүче Гөлзада Җамалиева икмәкнең ничек пешерелүе турында сөйли: «Ипи пешерү берничә этаптан тора. Иң беренче, бисмилланы әйтеп, күәс чиләге төбендә алдагы ипи пешергәннән калган бер уч тирәсе ипи башына җылымса су салып, ипи калагы



Гөлзада Җамалиева

белән болгатып йомшартабыз. Күәс – ипи камыры баса торган савыт. Элек аны агачтан яки балчыктан ясый торган булганнар. Андый савыт булмаса, зур, тирән кәстрүл дә ярый. Бу эш «баш кую» дип атала. Алдан әзерләп куелган җылы, иләнгән онны һәм ярты литр чамасы кайнаган җылымса суны (35-40 градус) салып, күәс чиләгендә ипи изәбез, ягъни әчетке ясыйбыз. Ул коймак камырыннан куерак булырга тиеш. Бик әйбәтләп, җиренә җиткереп, бер төер дә калдырмыйча болгатып, күәс чиләген яхшылап төреп, җылы урынга әчергә алып куябыз.

Камыр башы кичтән куела. Эшне иртә белән дәвам итәбез. Ипи салуның бу өлеше «ипи басу» дип йөртелә. 5-7 сәгать әчегән камырга тоз салабыз, яңадан он өстәп, кул белән басуны дәвам итәбез. Озак итеп кулга ябышмый башлаганчы басабыз. Яхшылап басып бетергәч, камырны әйбәтләп төреп, яңадан бер сәгатькә җылы урынга кабарырга куябыз. Аның әзер булуы тыгызлыгына, үзлелегенә карап болай билгеләнә: бармак белән өстенә баскач, барлыкка килгән чокырчык әкрен генә тигезләнә икән, димәк камыр әзер. Яңадан кабарып менгәч, кунага он салып, камырны төшерәбез, һәм ипи әвәлибез. Канат белән майланган табага яртылаш итеп камырны салып, савытны тутырганчы кабартырга җылы урынга куябыз.

Камыр кабарган арада мичкә утын ягып җибәрәбез. Мичнең юшкәсен (эшермәсен) ачабыз, бисмилла әйтеп: «Куәтле булып өлгер, ипиебезне матур итеп пешерергә ярдәм ит», – дигән теләкләр теләп, коры агачтан чыра телеп кабызабыз. Чыра өчен кулланыла торган агач (чырагач) алдан ук мич башына куеп киптерелә. Янып киткәч, мичкә утын өстибез. Күмер төшү белән, ипи тигез булып пешсен өчен, аны таратып җәябез. Утын янып беткәч, күмерләрне кисәү таягы белән казан астына, кече учакка тартып куябыз. Мичне томалыйбыз һәм мич пумаласына су бөркеп, төбен көлдән чистартабыз. Утын янып, мич кызган арада камыр да кабара. Кабарып чыккан ипиләрне кызу мичкә куеп, авызын капкач белән каплыйбыз. Шул ук вакытта сәгатькә карап калырга да онытмаска кирәк. Ипине мичтә нәкъ сәгать ярым тотасы. Шул вакыт эчендә берничә тапкыр мич капкачын ачып ипигә күз салабыз: ипинең йөзе килгәнме, артык кызарып китмәгәнме? Артык кызу булса, әзрәк мич капкачын ачып торырга да мөмкин.

Кызарып пешкән ипине табагач белән мичтән алабыз да, киндер ашъяулыкка төреп, мендәр өстенә каплап салабыз. Шулай суынганчы каплап тотабыз. Ипине борынгыдан калган гадәт буенча, күкрәккә куеп кисәбез».

Ипи кеше тормышының иң мөһим элементларының берсе. Биологик ихтыяҗларны канәгатьләндерү белән беррәттән, ул мөһим социаль функцияләрне дә башкара. Ипи тормышыбыз муллылыгын, туклыкны раслый.

Чыганаклар:
1. Баязитова Ф.С. Аш-су һәм халык традицияләре лексикасы. – Казан: «Дом печати» нәшрияты, 2007. – 480 б.
2. Әхмәтҗанов Ю. Икмәк кадере. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.
3. Әхмәтҗанов Ю. Татар халык ашлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.
4. Государственный архив Омской области. Ф. 1075. Л. 46.
5. Максуди Ахмад Хади. Гыйбадат Исламия. – Казань: Хузур, 2018. – 166 с.
6. Мәһдиев М. Бәхилләшү / Әсәрләр: 10 томда. 4 том. – Казан, Татар. кит. нәшр., 2015. – 512 б.
7. Салих Ф. Әни ипи сала. Электрон ресурс. Керү режимы: https://arsk.tatarstan.ru/.
8. Электрон ресурс. Керү режимы: https://tatar-today.ru/2018/10/36277/.

Миләүшә Әхәтова фоторәсемнәре

*Луиза (Лимуза) СОЛТАНОВА,*
*Татарстанның халык артисткасы,*
*«Тантана» республика театр премиясе лауреаты,*
*Р. Төхвәтуллин, Д. Кузаева исемендәге*
*премияләр лауреаты*



ҮЗ ГОМЕРЕБЕЗДӘ ЯЗМЫШ БЕЗНЕ КЕМНӘР БЕЛӘН ГЕНӘ ОЧРАШТЫРМЫЙ. АЛАРНЫҢ БЕРИШЛӘРЕ ШУНДУК ОНЫТЫЛА, КЕМНӘРДЕР ХӘТЕРДӘ ОЗАККА УЕЛЫП КАЛА. БУЛА ШУНДЫЙЛАРЫ – УЛ ОЧРАШУ СИНЕ ГОМЕР БУЕ ОЗАТА БАРА. ӘЛМӘТ ТЕАТРЫНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ АКТРИСАСЫ ЛУИЗА СОЛТАНОВА ОСТАЗЛАРЫН, АЛАР АРАСЫНДА АЕРУЧА БЕРСЕН – ЛӘЛӘ САДЫЙКОВАНЫ ИСКӘ АЛА.

# ОСТАЗЛАРЫМ

## САГЫНМАГАН КАЯ УЛ...

Әтием Миргазиян Солтангир улы Солтанов Азнакай районы Мәнәвез авылында туган. Бик яшьли әти-әнисез ятим калган, тамак туйдырыр өчен Азнакай урамнарында хәер сорашкан, аңа ягылган мунчада кунып чыгарга рөхсәт итә торган булганнар.

Көннәрдән бер көнне әти янына бер абзый килә дә: «Апаем, риза булсаң, әйдә, безгә кайтабыз, йорт эшләрендә булышырсың, тамагың тук, урының җылыда булыр», – ди. Ул Махиян исемле кеше булып чыга. Әти гомере буе бу гаиләгә чиксез рәхмәтле булды.

Өйдә аны өч малай каршы ала. Баксаң, аларның берсе Ләлә исемле кыз икән. Бик шаян иде, дип искә ала иде әти...

## БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУ

Балачактан әтиемнән «Артистка Ләлә апагыз» дигәнне еш ишетеп үстем. «Артистка» сүзе күңелгә балачактан уелып керде.

Мин VI сыйныф укучысы. Мәктәпкә каршы гына урнашкан клуб янына ят машина килеп туктады. Кемдер: «Болар Әлмәт артистлары!» – дип кычкырып җибәрде. Укытучыбыз артистлар белән очрашу булачагын әйтте. Я, Хода! Тәүге очрашу. Ике озын толымлы, зәңгәр күзле, килешле киенгән бер апаны Ләлә Садыйкова дип таныштырдылар. Әтиемнең «Артистка Ләлә апагыз» дигәне шушы матур ханым иде.

Ул елны һәр авыл мәктәбе район слетына концерт программасы әзерли иде, без дә артистларга шул программаны күрсәтәбез. Чират миңа җитте, мин үзем сайлаган «Дранча» көен җырладым. Ләлә апа яныма килеп, аркамнан сөйде дә: «Бер урында аз гына борма дөрес түгел, болайрак ул», – дип җырлап җибәрде. Нинди моң! Нинди тавыш! Әсәрләнеп тыңладым. Соңыннан яныма килеп: «Син Солтанов абыйлар кызы икән, кичкә спектакльгә килсеннәр, көтәм», – диде. Тагын җырны кабатлатты һәм: «Менә ич, хәзер бөтенләй дөрес», – дип миңа канатлар куйды. Район слетында җыр буенча беренчелекне алдым һәм без унлап бала Казанга Олимпиадага бардык. Бу 1957 ел



Г. Хугаевның «Кияүләр» спектакленнән күренеш

иде. Кечкенә генә авылдан башка бернәрсә дә күрмәгән бала өчен беренче мәртәбә поездга утырып Казанга бару – балачакның онытылмас хатирәсе.

### ТЕАТРДА ОЧРАШУ

1962 елның 2 апрелендә беренче көн театрга эшкә чыктым. Театр хәзер «Луч» телекомпаниясе эшли торган бинада урнашкан иде. Кечкенә генә авыл йортлары арасындагы бина бик матур, мәһабәт булып истә калды. Бүлмә түрендә бер өстәл, аның бер ягында бухгалтер Бриллиант апа, икенче ягында директор Фатих Хафиз улы утыра. Стена буйлап урындыклар тезелгән. Театрның бөтен байлыгы шул иде. Бина каршында декорация әзерләр өчен таш келәт бар, нәкъ суыткыч инде менә...

Шулай итеп, тормыш сукмагы мине Ләлә апа белән кабат очраштырды. Ул ике дә уйламыйча: «Фатир тапканчы, үзебездә торырсың», – дип кырт кисте. Бер бүлмәле фатирда мин җиденче кеше идем. Ә ничек матур яшәдек! Нинди киң күңеллелек! Үземне беркайчан



**Ш. Бикчуриннның «Тальян моңы» спектакленнән күренеш. 1961 ел**

да чит кеше итеп тоймадым. Күңелдә аларга карата мәңгелек рәхмәт хисе саклана.

## ҖЫРЛА, ҖЫРЛА...

Ләлә апа җырлы спектакльләрдә төп рольләрне башкарды. Ничек ярата иде аны тамашачы! Әнгам Атнабаевның «Ул кайтты» спектакле бара. Сюжет буенча, сугыш беткәнгә күп еллар узгач, Тимербулат авылына кайтып төшә. Марзыясы инде башкага кияүгә чыккан. Ләлә Садыйкова Марзыяның сеңелесе Саҗидәне уйный. Саҗидә-Ләлә җизнәсен кызгана, аңа соклана, гашыйк була. Өченче пәрдәдә ул болдырга чыгып, бик озын көй суза. Җырдан соң Саҗидәнең сүзләре бар. Тик ул аны әйтә алмый, чөнки тамашачы туктаусыз алкышлый. Ул җырны тагын кабатларга мәҗбүр була. Бу хәл бер генә авылда булса, язып та тормас идем. Ул һәр көн кабатлана иде. Мин мондый могҗизаны беркайчан да, бер театрда да, бер спектакльдә дә күргәнем булмады. Фәкать Ләлә апа җырлы рольләрен башкарганда гына була иде бу хәл, тамашачы аны сихерләнеп тыңлый иде...

## ИҖАТТА ҮТКӘН ГОМЕР

Җитмәүчелек, хезмәт хаклары кечкенә, кайбер колхозларда он бирсәләр, артистларга тигез итеп бүләләр, гаилә булмагач, мин үз өлешемне башкаларга, я Ләлә апага бирәм. Аларның йөзендә рәхмәт шатлыгын күреп, ләззәт кичерә идем.

Гомер юлда уза. Салкыннарда өшибез. Андый чакта Ләлә апа: «Аягың өшегән, кил әле», – дип, пальтосын чишеп, аякларымны эченә тери. Ничек кенә чирләсәк тә, беркайчан спектакльне өзмәдек.

Өлкән буын артистларыбызның берсе дә юбилейлар, банкетлар, санаторийләр һәм шундый башка кадер-хөрмәт тоеп яшәмәде. Диварларына бәс сарган салкын клубларда ил тыныч булсын, театр яшәсен, тамашачы яратсын һәм иң мөһиме – план тулсын дип янып иҗат итте! Ә тамашачы үз баласын яраткан кебек, ихлас мәхәббәте белән кочагына ала, кунак көткән кебек каршылый, шыгрым тулы заллар белән озатканда, күз яшьләре аша: «Тизрәк килегез, сезне генә көтеп яшибез», – дигән гаҗәеп сүзләр белән озатып кала.

**МИН ӘЛЕ ДӘ СЕЗГӘ ДӘШӘМ**

Пенсиягә чыгасы елларда бакча җире алдыгыз, Ләлә апа. Җиң сызганып эшкә чумдыгыз, яратып эшләдегез, чүп үләне үскән җирдә гөлбакча булдырдыгыз.

Хәтерлим – бер язда: «Быел алма булырга тиеш», – дип фаразладыгыз. Ул елны алмагачтан ике зур алма өздегез. Аның да берсен генә өйдәгеләргә авыз иттердегез, икенчесен театрга алып килеп, барыбызга да өлеш чыгардыгыз. Андый тәмле алманы башка ашаганым булмады кебек.

Сезнең күршедә Дамирә Кузаева һәм Фоат Зариповлар бакчасы иде. Җиләк-җимеш өлгергәч, барыгыз да труппаны кунакка чакырасыз, нәрсә өлгергән – шуны җыярга рөхсәт бирә идегез. Без җыябыз, көлешәбез, мунча керәбез, кичен җыелып утырып, әлбәттә, сезнең җырлауны сорыйбыз. Сез җырлаганда ирегез Зәкәрия абыйны күзәтәбез. Әй ярата иде дә ул сезнең җырлауны! Күзләре еракка төбәлә, үзе дә сизмәстән, рәхәт итеп пеләшен сыйпый... Ниндидер сихри дөньяга күчеп, Сезгә мәхәббәтен аңлата кебек тоела иде безгә. Җыр бетүгә, күрше йорт тәрәзәсеннән: «Ляля, еще раз спой, пожалуйста», – дигән тавыш ишетелә.

Гаилә дусларыгыз арасында танылган шәхесләр бик күп иде. Саҗидә Сөләйманова белән ире Әдип абый Маликов, Башкортстаннан Фәридә Кудашева белән ире Бәхти Гайсин... Минзәлә театрыннан гаиләле артистларның шактые кунак була иде сездә. Ул кичләрдә уртак сүз, әлбәттә, җыр-моң, сәнгать кешеләре, театр, поэзия тирәсендә кайный.

**САГЫНМАГАН КАЯ УЛ?!.**

Бу язмамда Ләлә апа исеменә басым ясасам да, аның янәшәсендә эшләгән барлык иҗади труппа күз алдымда. Сезнең һәр кайсыгыз китап язарлык зур шәхесләр!

Барый ага Гатауллин белән тормыш иптәше Камилә апа. Икесе дә шәп актерлар, өстәвенә иң оста грим салучылар да. Театр студиясендә грим дәресен алар укытты. Барый агай рәссамлык эшен яратты, хәтта «Таһир-Зөһрә» спектаклендә рәссам-бизәүче вазифасын үтәде. Ә нинди фотограф иде ул! Ул булмаса, бүгенге көндә театр музеебыз тарихи яктан шактый ярлы булыр иде.

Тайфур абый Кичубаевлар гаиләсе, хатыны Гөлҗиһан апа, аның сеңелесе Җиһан Сәетовалар. Алар нәфис сүз осталары, аерым концерт программасы әзерләп концерт куялар. Ә Җиһан апа өздереп баянда, гармунда уйный, бик күп спектакльләрдә музыка өлешен гармунда уйнап, үзе алып бара иде.

Әгъзәм Галиуллин... Ул комик һәм трагик актер иде.

Әхмәт агай Галиакбәров. Бер көнне «Ул кайтты»да Тимербулатны уйнап, бөтен залны елатса, икенче көнне «Тальян моңында»гы комик образы белән көлдерә. Ә тормышта иң оста кәрзин үрүче, һәм ул аларны күз ачып йомганчы сатып бетерә иде. Тормышта акча җитмәүлекне шуның белән ялгагандыр.

Ирле-хатынлы Кави Бариев һәм Диләрә Хисаметдинова. Без – яшьләргә бик акыллы фикерләрен сеңдереп әйтә беләләр иде. Кави абый гармунда, курайда оста уйный. Концертларда Диләрә апа башкорт көен сузып җибәрә, ә Кави абый курае белән җырны тагын да тулыландыра... Җитмәсә, Кави абый бик оста көмешче дә. Ул елларда алам дисәң кибетләрендә дә юк. Ә Кави абый образга тәңгәл матур алкалар, көмеш беләзекләр, муенсалар эшләп, күпләребезгә бүләк ясады.

Хәлимә Маннуровада опера җырчыларына хас тавыш. Музыка белгечләре аны укырга китәргә кыстады. Әмма тормыш авырлыклары актрисага андый мөмкинлек бирмәде. Ире Зәки Газыймҗанов та озак еллар театрда эшләде. Гаҗәеп оста баянчы иде ул.

Әминә апа Садыйкова, Рамазан Ихсанов, Гыйлемхан Камалов, Разия Нураева, Рәйсә Гобәйдуллина, Илгизәр Кәтиев, Мәдинә Ямангулова, ире Ибраһим Әбләминов – нинди соклангыч артистлар! Ә Зәкия Туешева?! Театрыбызның олпат шәхесе, абруйлы актриса, режиссер, сугыш ветераны, шәһәребезнең мактаулы гражданины. Бөтен гомерен театрга багышлаган талантлы кешебезне былтыр соңгы юлга озаттык. Күңелләребездә бушлык.

Остазларым, сез иң авыр елларда театрны тудырдыгыз, сакладыгыз, иҗади үрләр яуладыгыз, татар халкы яшәгән иң кечкенә ерак авылларга да театр сәнгатен ирештер-



Т. Миңнуллинның «Яшьлегем җүләрлегем, яшьлегем гүзәллегем» спектакленнән күренеш

дегез. Раббым, барыгызның да урыннары оҗмахта булсын! Амин!

Театрыбызда бик мактаулы гадәт яши: без ел да май аенда зиярәт кылабыз, каберлекләрне чистартабыз, коймаларын буяп яңартабыз, чәчәкләр куябыз. Һәммәгез янында туктап, театр яшьләренә сезнең хакта сөйлибез. Ул көнне күңел хушлыгы тоябыз, сезнең белән очрашкан кебек булабыз. Иншаллаһ, бу эшебез киләчәктә дә дәвам итәр!

Олы кызыгыз Одинә Иркутск шәһәрендә яши, сеңелесе Зөлфия Финляндиядә тора. Алар үзара сөйләшеп, җәй көне Әлмәткә кайткач, минем белән очрашу билгелиләр. Теләкләре бер – әти-әниләре турында күбрәк белү. «Гел гастрольдә йөрү сәбәпле, без аларны сирәк күрдек, ә сез, киресенчә, бергә юлда булдыгыз. Сөйләгез», – диләр. Мин сөйлим, көлешәбез, елашабыз, аңлашабыз, кунакларга чакырышабыз, кабат күрешүләр теләп, саубуллашабыз.

## ЭХ, БҮГЕНГЕ ТЕАТРНЫ КҮРСӘТӘСЕ ИДЕ!

Бүгенге көндә театр чагыштырмача оҗмах шартларында яши дисәк, дөрес булыр. Якты, җылы, зәвыклы бизәлгән заллар, уңайлы шартлар. Дөньякүләм танылган фестивальләрдә катнашабыз, Россиянең кайсы гына төбәгендә гастрольдә булмый театр. Эх, бүгенге театрыбызның яшәешен күрсәтәсе иде сезгә! Мөгаен, барыгыз да, Аллага шөкер, без башлаган эш дәвам итә, театр яши, йөзебезгә кызыллык китермисез, рәхмәт сезгә, дияр идегез.

Ләлә апа, шуның белән Сезгә бу хат-хатирәмне тәмамлыйм. Бигрәкләр дә ялан аяк йөрергә яраттыгыз. Сез атлаганда дөк-дөк аяк тавышыгыз ишетелеп тора иде. Ә җиргә нык басып йөрүчеләр – тынгысыз җаннар бик кирәк!

*Гөлназ САДЫКОВА,*
*Арча, 5 нче «Кояшкай» балалар бакчасы тәрбиячесе*

# Арча. Гөслә. «ЯТАГАН»

ЯТАГАН – БОРЫНГЫ КЫЛЛЫ ЧИРТМӘ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЫ. ӘММА АРЧАЛЫЛАР ӨЧЕН УЛ УЕН КОРАЛЫ ГЫНА ТҮГЕЛ, ФОЛЬКЛОР АНСАМБЛЬ ИСЕМЕ ДӘ. АНСАМБЛЬНЕҢ ҖИТӘКЧЕСЕ – ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН МӘДӘНИЯТ ХЕЗМӘТКӘРЕ АЛЬБЕРТ СӘЛАХ УЛЫ ГАЙНЕТДИНОВ.

**Белешмә:** *Альберт Гайнетдинов тумышы белән Минзәлә районының Бикбау авылыннан. Баян классы буенча Әлмәт музыка училищесын тәмамлаган, Казан мәдәният институтының халык уен кораллары бүлегендә укыган. Бик теләп, яратып укый ул анда, чөнки халык уен кораллары аңа яшьтән үк якын була. Укуын тәмамлаганнан соң тормыш юлы аны Арча музыка мәктәбенә илтә. Армия сафларында хезмәт иткәндә тынлы оркестр оештыра. Хәрби хезмәтеннән соң, кабат Арча музыка мәктәбенә кайта. 1977-2012 елларда биредә мәктәп директоры була, хәзер дә, лаеклы ялда булса да, музыка дәресләре алып бара.*

Арча сәнгать мәктәбенең гөслә тарихы 2012 елдан башлана. Альберт ага татар гөсләсе белән кызыксына башлый – үзешчән музыкант Сәет Шәрәфиев ясап биргән татар гөсләсендә уйнарга өйрәнә. «Арча сәхнәләрендә гөсләчеләрне күргәнем бар иде, шул вакытта ук бу уен коралы минем игътибарымны җәлеп итте. Әкренләп өйрәндем», – ди Альберт ага.

Арча сәнгать мәктәбенә икенче гөсләне «Сорнай» фольклор ансамбле җитәкчесе Ринат Гыйләҗев ясап бирә. Шулай итеп, гөслә дә яңартыла, уйный-уйный үзе дә остара: Альберт ага төрле этномәдәни конкурсларда призлы урыннар да яулый башлый. Шул исәптән, «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивалендә дә катнаша.

Бераздан Альберт Гайнетдинов ансамбль турында уйлана башлый. Әле кемнәр уйнаячагын күзаллап бетермәсә дә, ансамбльнең булачагана ышана: тагын ике



гөсләгә заказ бирә. Әлбәттә, бу эшкә теләсә кемнең алынмаячагын һәм алына да алмаячагын ул бик яхшы аңлый, чөнки гөслә танылган музыка уен коралы түгел. Музыкантның беренче фикердәшләре концертмейстер Земфира Хәсәнова һәм үз кызлары – Айгөл Гарифуллина һәм Айсылу Мортазина була – сәхнәгә ул алар белән чыга.

Ниһаять, 2017 елның февралендә, гөсләчеләр ансамбле оеша: ансамбльгә музыка мәктәбе укытучысы Айгөл Исмәгыйлева, соңрак Резидә Зиннәтуллина кушыла. Коллектив беренче чыгышын «Арча көе» белән башлап җибәрә, бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яулый, Сабантуйларда осталык дәресләре бирә.

2017 елның сентябреннән башлап, ансамбль «Ятаган» исемен йөртә һәм бәйгеләрдә ул шушы үзенчәлекле, җанга ятышлы матур исеме белән катнаша. «Этномириада», «Татарстан – безнең йортыбыз», «Кунаклашу», «Сокровища нации», «Уйнагыз, гармуннар!», «Этнофония», «Урмай-Зәлидә», «Моңлы курай», «Халкым мирасы», «Караван наследия» – музыкаль коллектив катнашкан бәйгеләрнең кайберләре. Бәйгеләр Татарстан белән генә чикләнми, арчалылар күрше республикаларга да чыга.

Вакытлар үткән саен ансамбль зурая һәм камилләшә. Булат Сафиуллин (бас инструменты һәм җырчы), Миләүшә Сәгыйтова (гөслә), Альбина Гомәрова (скрипка), Әлфия Баһаветдинова (гөслә), Артур Хафизов (солист), Динар Бариев (баян-гармун), Айгөл Хәбибрахманова (мандолина һәм бәрмә уен кораллары), Дамирә Мөхәммәдиева (гөслә) кушылгач, ниһаять, 14 кешедән торган состав барлыкка килә. Әлбәттә, аның төп өлешен гөсләчеләр алып тора. Чөнки ансамбльнең оештырылу сәбәбе дә гөсләчеләрне үстерү, онытмау, пропагандалау максатыннан була, ләбаса.

Ансамбль тарихындагы тагын бер якты мизгел – тырышлык, күп көч куеп эшләү бушка китми: коллектив 300 000 сумлык грант ота. Бу акчага яңа музыка уен кораллары алына, костюмнар тегелә.

Альберт Гайнетдиновның сәхнә эшчәнлегендәге олы тәҗрибәсе, традицион музыка кораллары буенча тирән белеме, үз хезмәтенә ихлас бирелгәнлеге, югары дәрәҗәдә эшкә сәләте, музыка коралларында оста уйнавы, үзенә дә, башкаларга да таләпчәнлеге чын мәгънәсендә могҗиза тудыра: кыска гына вакыт эчендә ансамбль профессиональ коллектив булып формалаша. Ансамбльнең кабатланмас үз йөзе барлыкка килә.

Ансамбльнең зур уңышы – киңәш бирерлек һәм кирәк кадәр генә үсендереп торырлык профессионаллар белән элемтәдә булуы. Әйтик, ансамбльгә гөсләләрне һәм ятаганны Йошкар Оланың татар музыка үзәгенең музыканты һәм алтын куллы остасы Гәрәй Мәгъсүмҗанов ясап бирә. Шулай итеп, ансамбльгә өч гөслә һәм ике ятаган кайтартыла. Коллектив фольклорчы галим, традицион инструментлар буенча зур белгеч, Казан дәүләт консерваториясе доценты Геннадий Макаров белән бик яхшы мөнәсәбәтләрдә. «Бөтен борчыган сорауларыбыз һәм тәкъдимнәребез белән һәрвакыт аңа мөрәҗәгать итәбез», – ди ансамбльнең сәнгать җитәкчесе. Геннадий Макаров ансамбль заказы буенча ике думбра да ясап биргән. Шулай ук, Казан консерваториясенең музыка сәнгате факультеты деканы, профессор Сәгыйть Хәбибуллин белән дә аралашып яшиләр, ул үзенең төпле киңәшләре белән ярдәм итеп тора.

Ансамльнең репертуары да баеганнан байый: татар халык җырлары, такмаклары, биюләре һәм композиторларның әсәрләре урын ала. Татар халкының асыл мирасы булган милли моңнарыбызны, гореф-гадәтләребезне, уен-йолаларыбызны торгызып, туплап, янәдән халыкка ирештерүче бу коллектив – Арча шәһәренең музыка сөюче халкы өчен көтеп алынган кунак.

Альберт Гайнетдинов һәм аның сәхнәдәшләре киләчәктә ансамбльгә яңа уен коралларын – кыя-кубыз, җәя-кубызны да кертергә хыяллана. Аларның җырчылар һәм биючеләр өстәп, Татар халык җыр һәм бию фольклор музыкасы төркеме төзисе килә. «Эшебезне дәвам итәчәкбез, моның өчен мәктәбебездә бөтен мөмкинлекләр тудырылган», – ди Альберт Гайнетдинов.

Без аларга зур уңышлар һәм яңа үрләр яулауларын телибез!

Фоторәсем Альберт Гайнетдиновның шәхси архивыннан

*Әңгәмәдәш –*
***Фәния ЛОТФУЛЛИНА***

# Айгөл Бариева:
## *«Мөнәҗәтләр көйләү күңелемне тынычландыра»*

«ЧАБАТА», «КИЛЕН ТӨШКӘНДӘ», «СӘЛАМ СИҢА, АВЫЛДАШЫМ», «ТУЙ ЖЫРЫ», «МИН СИНЕ ШУНДЫЙ САГЫНДЫМ»... БУ ҖЫРЛАР ПОПУЛЯР ЭСТРАДА ҖЫРЧЫСЫ, ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН АРТИСТЫ АЙГӨЛ БАРИЕВА РЕПЕРТУАРЫННАН. ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮҢЕЛЕН ЯУЛАГАН ШУШЫ МӘҢГЕЛЕК ҖЫРЛАР БЕЛӘН БЕРРӘТТӘН, ЯҢА ҖЫРЛАРЫ БЕЛӘН ДӘ СӨЕНДЕРЕП ТОРА УЛ ТАМАШАЧЫСЫН. СОҢГЫ ЕЛЛАРДА МӨНӘҖӘТЛӘР ДӘ БАШКАРА.

ПОПУЛЯР ҖЫРЧЫ БҮГЕН НИЧЕК, НИНДИ УЙ-ХЫЯЛЛАР БЕЛӘН ЯШИ, ТОРМЫШЫНДА, ИҖАТЫНДА НИНДИ ЯҢАЛЫКЛАРЫ БАР? ӘҢГӘМӘБЕЗ ӘНӘ ШУЛ ХАКТА.

**– Айгөл, әйдә, сүзебезне әти-әниеңнән башлыйк әле. Чөнки син Шамил Бариевның кызы буларак та күпләрнең күңеленә кергән җырчы. Әле менә яңа ел алдыннан гына Сабада әтиең – Камал театрының күренекле артисты Шамил Бариевны искә алу кичәсе булып үткән иде. Бу кичәдән нинди тәэсирләр белән кайттың?**

– Әтиемнең тууына 70 еллыгы уңаеннан аның туган ягында бик матур кичә дә уздырдык. Бирегә якташлары, сабакташлары, төркемдәшләре, үзе укыткан укучылары килде – хатирәләрне яңарттык. Бөтен эшләрен читкә куеп, Әлмәт, Минзәлә, Чаллы якларыннан шушы кичәгә кайтучы әтинең шәкертләренә бик рәхмәтлемен. Аларның бүген һәрберсе үз юлын тапкан, танылган шәхесләр. Бик җылы, бик мәгънәле кичә булды.

**– Айгөл, әниең – Гөлфия апа белән тавышыгыз шулкадәр охшаш икән...**

– Казанның хәзерге Ленин исемендәге мәдәният сараенда Суфия апа Шаһиева җитәкчелегендәге бик көчле хор бар иде. Әти белән әни шунда танышалар. Бу хор белән алар гастрольләргә дә йөриләр. Хәтта Мәскәүгә барып, Кремль залында да чыгыш ясарга насыйп була аларга. Әнием бик матур җырлый иде. Мәскәүдән килгән профессор аны консерваториягә дә чакырган. Дәү әнием генә җибәрмәгән. Әни гомер буе балалар бакчасында музыка җитәкчесе булып эшләде. Бүгенге көнгә кадәр радиода оркестр белән язылган язмалары саклана.

Без бергә гаилә концертлары куя идек. Миңа 14 яшь булганда бер айга Саба районы авылларына гастрольгә чыгып киттек. Үзебез белән баянчыбыз Хәмит Кәримовны, Камал театры артисты Хәлим Җәләйне





алдык. Мәдәният йортлары шыгрым тулы була иде. Бернинди аппаратурасыз, тере тавышка концертлар бирдек. Бүгенгедәй истә ул күңелле чаклар...

Әти белән әни гомер буена бербөтен булып яшәде. Әти безне үзе белән гастрольләргә дә алып бара иде, әнине дә беркайчан да үзеннән калдырмады. Яратулары шулкадәр көчле иде, әни әтисез озак яши алмады. Пар аккошлар кебек бер-бер артлы китеп бардылар.

**– Менә шундый матур, мәхәббәтле гаиләдә генә талантлы кызлар үсә. Син сәхнәдәге беренче адымнарыңны данлыклы «Сорнай» ансамблендә башлап җибәргән кеше. Шул чакта күңелеңә салынган халык җырларына, уен коралларына мәхәббәт бүгенге иҗатыңда да чагыла.**

– 1991 елда Казан мәдәни үзәгенә эшләргә килдем. 30 ел элек! Ул вакытта Ренат абый Гыйләҗев җитәкчелегендә «Сорнай» ансамбле эшләп килә иде. Мине шунда солистка итеп билгеләделәр. Ренат абый безне бик күп нәрсәгә өйрәтте. Нәкъ менә шунда думбра, курай, сорнай кебек халык уен кораллары белән якыннан таныштым.

Репертуарга килгәндә, халкыбызның борынгы, сирәк яңгырый торган җырларын башкара идек. Төрле төбәкләргә чыккач, мәсәлән, Урал татарларының, Себер татарларының фольклор үрнәкләрен өйрәнеп, сирәк яңгырый торган җырларны яздырып кайта идек. Биредә эшләү миңа бик зур тәҗрибә булды. Сәнгать юлымны нәкъ менә шундый ансамбльдән башлап җибәрүемә әле дә сөенәм. Ул миңа киләчәк иҗатымда да нык ярдәм итте.

Миңа хәтта «Сорнай» белән үз гомеремдә беренче тапкыр чит илгә чыгу бәхете дә тәтеде: 1993 елда Финляндиягә барып кайттык. Ул вакытта әле бөтен илләр ябык, чит илгә чыгу, гомумән, бик зур вакыйга иде. Поезд белән баруларны, фин татарлары белән танышып күрешүләрне мәңге онытмыйм. Чикне узгач, тәрәзәгә карауга ук чит ил икәне күренә – андагы тип-тигез урманнар, тип-тигез җирләр... Әйтмәсәләр дә, Финляндиягә кергәнеңне аңлыйсың. Ул вакытта бездә супермаркет дигән кибетләр дә, кәрәзле телефоннар да юк. Үзгәртеп кору чоры бик авыр еллар иде. Мәңге онытмыйм – фин татарларының әйдәп йөрүчеләреннән берсе Акиф Али үзенең кәрәзле телефонынннан әнием белән сөйләштереп, хәйран калдырган иде. Андагы гомер күрмәгән супермаркетлар, рестораннардагы швед өстәлләре турында сөйләп тә тормыйм.

Безнең өчен икенче дөньяга килеп эләккәндәй булды ул.

Икенче гастроль дә бик нык истә калды. 1995 елда Төрки халыклар фестиваленә юл тоттык. Ул 51 көнгә сузылды. Аны Төркиядә яшәүче милләттәшләребез оештырган иде. Төркиядә тугыз көн, аннан соң Европага чыгып, Австрия, Германия, Швецария һәм башка илләрдә йөреп, янәдән Төркиягә кайтып концертлар куйдык. Без анда өчәү бардык: Ренат абый, мин һәм нәфис сүз остасы Розалия Шаһиева. Өчебез бөтен Татарстанның милли сәнгатен күрсәтергә тиеш идек. Мин җырчы буларак тулаем бөтен программаны башкардым, Ренат абый уен коралларында уйнады, Розалия апа туган телебезнең матурлыгын нәфис сүз аша җиткерде. Бик җаваплы эш иде һәм без аны намус белән башкарып чыктык.

**– Рамазан аенда интернетка мөнәҗәтләр дә яздырып элгән идең. Бу жанр белән кайчан кызыксына башладың?**

– Кечкенәдән үк дәү әнием көйләгән мөнәҗәт-бәетләрне тыңлап үстем. Аның мөнәҗәтләр язылган дәфтәре дә бар иде. Кайбер көйләрне үзе дә чыгара иде. Бик күптәннән мөнәҗәтләр башкарырга, дөрес итеп көйләргә өйрәнергә кызыга идем. Ике ел элек Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге хезмәткәре Лилия Җиһаншина мине Рамазан аенда ифтарга чакырды. Шунда аның бик матур итеп мөнәҗәтләр көйләгәнен ишетеп таң калдым һәм миңа да өйрәтүен сорадым. Рәхмәт яусын, Лилия миңа берничә мөнәҗәтнең ноталарын, сүзләрен бирде, көйләп күрсәтте. Шулай өйрәндем. Киләчәктә бу эшне дәвам итәргә уйлыйм. Мөнәҗәтләр көйләү миңа бик тә ошый, күңелемне тынычландыра, рәхәтлек бирә. Иң беренче мөнәҗәт башкарганда, хәтта ирексездән күземнән яшьләр тәгәрәде. Мөнәҗәтләрнең ниндидер сихри көче бар, дәвалау көче дип тә әйтер идем. Аларны көйләп тынычланасың, чистарынасың.

**– Һәр җырчыны җырчы иткән, аны тамашачыга таныткан бер җыры була. Шундый бер җырыңның тарихын сөйлә әле.**

– Андый җыр «Чабата»дыр инде ул. Кая гына барсам да, аны гел сорыйлар. Ул җырга 26 ел! Аны «халык җыры» дип тә атаганнар. Ләкин ул Илсур Хөснетдинов шигыренә Зөфәр Хәйретдинов язган җыр. Шушы җыр өчен Зөфәр абыйга мең-мең рәхмәтлемен – мине шул җыр танытты. Заманында хәтта бу җырны Дмитрий Крыловның «Не путевые заметки» тапшыруында меңъеллык Казан турында сөйләгәндә фон өчен файдаланганнар иде. Мин шаккаттым: күпме җыр бар, алар нәкъ менә шул җырны сайлап алганнар. Бәлки, дәртле, милли төсмерләргә бай булуы белән үзенә җәлеп иткәндер. Шулай тарихка кереп калдык. Мин хәтта Дмитрий Крыловның үзе белән элемтәгә чыктым. Ул миңа тапшыруны дискка яздырып бүләк итте.

**– Хәзер югары сәнгатькә ихтыяҗ кимеде, халыкның зәвыгы түбән тәгәрәде, дип сөйләргә яратабыз. Моның белән килешәсеңме? Милли сәнгатебезне бозмыйча, чәчми-түкмичә саклап калырга һәм яшьләребез дә кызыксынырлык итеп ничек киләчәк буынга җиткерергә?**


– Бар нәрсә дә үз кулыбызда. Мәсәлән, күптән түгел генә Татарстанның халык артисты, шәхсән үземнең бик яраткан җырчым Вафирә апа Гыйззәтуллинаның тууына 75 ел тулды. Шушы юбилей уңаеннан берәр нинди чара үттеме?! Ул бит йолдыз! Аның сәнгате сөйләп бетерерлек һәм бер кичәдә күрсәтеп бетерерлек тә түгел. Әйе матди яктан ярдәм булмаса, эшләп булмый. Алла теләсә, шундый кичә үткәрергә ниятем бар. Яшьләргә ул башкарган әсәрләрне тыңлатып, аның әсәрләрен башкарып... Искиткеч концерт булган булыр иде ул. Чөнки ул башкарган җырлар шулкадәр матур. Алар бит халкыбыз тарихының алтын ядкарьләре! Менә шундый сәнгать әһелләребез бик күп.

Яшьләрнең фикере бик тиз үзгәрә, шуңа күрә, ничектер аларга яраклашып кына элеккеге көйләрне үзгәртергә кирәкми дип уйлыйм. Бай мирасыбызны түкми-чәчми ничек бар шулай үзгәртмичә, буыннан-буынга тапшырырга кирәк. Ә сәнгатькә килгәндә ул төрле булырга тиеш. Шуңа да татар сәнгатенең киләчәге бар дип саныйм.

Фоторәсемнәр Айгөл Бариеваның шәхси архивыннан

# ЯҢА КИТАП

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНДА УРТА ГАСЫР ТАТАР ӘДИБЕ МӨХӘММӘДЬЯРНЫҢ «НУРЫ СОДУР» ИСЕМЛЕ КИТАБЫ ДӨНЬЯ КҮРДЕ. КИТАП ФИЛОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ ДОКТОРЫ ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВНЫҢ «ГАДЕЛЛЕК ҖЫРЧЫСЫ МӨХӘММӘДЬЯР» ИСЕМЛЕ КЕРЕШ МӘКАЛӘСЕ БЕЛӘН БАШЛАНЫП КИТӘ. ӘСӘРЛӘРНЕҢ ТӘНКЫЙДИ НӨСХӘСЕН, ХӘЗЕРГЕ ТЕЛГӘ ТӘРҖЕМӘСЕН, ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ АҢЛАТМАЛАРНЫ ГАЛИМ ШАКИР АБИЛОВ ӘЗЕРЛӘГӘН.




Әлеге китапта Мөхәммәдьярның ике мәшһүр поэмасы – «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур» һәм «Нәсыйхәт» исемле шигыре тәкъдим ителә. (Бүген без сезгә шул әсәрләрдән өзекләр тәкъдим итәбез.) Шагыйрь яшәгән еллар – Казан мәмләкәтенең, гомумән, татар халкының катлаулы, каршылыклы чоры. Бу хәлне күргән, кичергән шагыйрь читлектәге кош кебек бәргәләнә, өзгәләнә, илне һәлакәттән коткарып калырга омтыла. Ул ил язмышы белән борчылып, аның киләчәген кайгыртып яши. Аның рухи дөньясы, шатлыгы, борчылулары әсәрләрендә урын ала.

«Төхфәи мәрдан» («Егетләргә бүләк») поэмасында Кеше образы үзәктә тора. Иң ләззәтле гамәл – кешегә яхшылык эшләү; начар эшнең һәркайсын җәза көтә. Моңа ул мисаллар китерә. Чын ир-егетнең омтылышы, идеалы да олы булып, ул башкарырга тиешле эшләр дә аның исеменә тиң югары, бөек булырга тиеш. Әсәр кече форматлы алты хикәят белән тулыландырылган.

## Төхфәи мәрдан

**(Егетләргә бүләк)**

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим
Илаһи, Син юмарт, ризык бирүче,
Бер Син, бар Син, рәхим, гафу итүче.
Хәсрәтленең сердәш дусты, яры Син,
Һәр мескенне дәвалаучы бары Син.*

*Яхшы күреп, күтәр мине туфрактан, –
Аерырсың Син караны һәм актан.*

*Рәхим итеп, үргәчә бир абруй,
Шәфкать итеп, «Гөнаһым китаб»ын җуй.*

*Күрешү бәхтеннән җанымны шат кыл,
Күңелемне гамь-кайгыдан азат кыл.*

*Серебезне белүче Син, бөек зат,
Җәүребезне гафу ит Син, юмарт зат.*

*Барлык мәзлүм-мескеннәргә пәнаһ Син,
Гаеп эшебезне кичер, Илаһ, Син.*

*Сайлап алган рәсүлеңнең хакына –
Бүләк иттең җилән аның хакына.*

*Рәсүлләрнең имамы – дус Мөхәммәд,*
*Юл күрсәтүче, яклаучы – Мөхәммәд.*

*Әбүлкасыйм аңа ләкаб булды, бел,*
*Аны сыйфатларга җитмәстер йөз тел.*

*Таҗ, тәхетнең һәм әләм шаһин шаһы,*
*Пәйгамбәрләр, кеше, гаскәрләр шаһы.*

*Ул – бөтен галәм ияse, сөйгән зат,*
*Аның пакь рухына сансыз салават.*

*Туфрак, суга бүлмә барлыгын аның, –*
*Ул үзе бер гүзәл җисем, пакь җаны.*

*Мигъраҗда сөенеп ике теләктән,*
*Аксадан Мәккәгә барды ул өстән.*

*Мәңгелектә Ходай кылган язмышы:*
*Бергә иде һәм Җәбраил – юлдашы.*
*Борынгыдан шулай калган ул дәлил,*
*Рәсүл китте, калды юлда Җәбраил.*

*«Бу җир, – диде Җәбраил, – чиктер миңа,*
*Бу чәчәклек яхшы урындыр миңа».*

*Шөһрәтледән Җәбраил калды карап,*
*Аннан түгел, Үзеннән ярдәм сорап.*

*Рәсүл җитте бер җиргә, ул шундыйдан, –*
*Сыймас анда яратылган җисме җан.*

*Нинди яхшы! – Мостафа, – рәсүллә хәтме,*
*Ике дөньяның сайланган рәхмәте.*

*Барлык ихтирамга ия башлык ул,*
*Кыю имамнарның җитәкчесе ул...*

«Нуры содур» («Күңелләр нуры») поэмасы гаделлек нигезенә корылган идеаль дәүләт турындагы хыял белән сугарылган. Биредә ун хикәят бәян ителә. Бу әсәр әүвәл Казан, соңыннан Кырым ханы булган Сәхибгәрәйнең үтенече белән язылган. Ул җирдәге тормышны кешеләрнең матур яшәү һәм тыныч хезмәт урыны санап, аның шулай булырга тиешлегенә ышанып карый, гаделлек идеясен җәмгыятьне савыктыруда һәм аның алга таба үсешен тәэмин итүдә бердәнбер юл итеп күрә.

## Нуры содур

**(Күңелләр нуры)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим
Барча серләрне беләсең, Илаһым,
Мин – языклы колың, күптер гөнаһым.
Беләм: гөнаһым җәзасын китерер,
Мәгәр күз яшьләрем гафу үтенер.

Синнән башка юктыр һичбер тереклек,
Син үзең ул мәңгелек бер тереклек.

Кешеләрне йөз аклыгы өчен дә
Шат ит монда, теге дөнья эчендә.

Ике дөнья хуҗасы – соңгы рәсүл,
Пәйгамбәрләр башлыгы – соңгы рәсүл.

Рәсүленә Хак хөрмәтен белдергәч,
Пәйгамбәрлек таҗын аңа кидергәч,

Бары да аннан үзенә нур тапты,
Оҗмах рәхәтлеге һәм дә хур тапты.

Дөнья һәм галәм җаныдыр Мөхәммәд,
Тәүге, соңгы пәйгамбәрдер Мөхәммәд, –

Рисаләт мәйданының шаһин шаһы,
Пәйгамбәрләр башлыгы, шөһрәт таҗы.

Хак сөйгәне – барчага рәхмәт үзе,
Гөнаһлылар яклаучысыдыр үзе.

Үзләренең пакь рухына һәрвакыт
Әйтик йөз мең дога-сәлам һәрвакыт.

Чиксез ярдәм кыямәт көнне безгә –
Хак рәсүле рухыннан булыр безгә.

Киң күңелле Хода, барын белүче,
Мостафаны ит ярдәмгә килүче.

Әбүбәкер – сердәш дуст һәм саф йөзе,
Гомәр – һәрчак дингә катыдыр үзе.

Госман – юаш, оялчандыр торышта,
Гали арысландай үзе орышта.

Бере – дусты, бере – арыслан аның,
Бере – җыйнаучы, бере – галимнән аның.

Кайчандыр ул мәхшәр көне булганда,
Җирнең өсте халык белән тулганда,

Аерылмасын алардан бу – бер гидай,
Рәхмәтеңнән кичер халыкны, Ходай...

**Язманы Наилә ЗЫЯТДИНОВА әзерләде,**
**Татарстан китап нәшрияты хезмәткәре**



**Адилә МӨГЫЙНОВА (14 яшь) рәсеме,**
**Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы**

# Газиз телем – Тукай теле!

Матур минем балачагым,
Изге минем ниятләрем.
Сабый чактан тыңлап үсәм
Тукай абый әкиятләрен.

«Бишек җыры»ннан башлана
Балаларга яхшы теләк.
«Су анасы», «Шүрәле»се –
Буыннарга күчәр бүләк.

«Шаян песи», «Акбай»ларын
Укыйбыз без гаилә белән.
Аның шигырьләре аша
Дөньяны мин күбрәк беләм.

Ә шулай да күңелемдә
Кадерлесе – «Туган тел»е.
Иң матур тел, иң затлы тел –
Газиз телем – Тукай теле!
Татар теле!

**Гөлнара ГАЛӘВИЕВА,**
**Казан, 7 нче балалар бакчасы**
**татар теле тәрбиячесе**



**Динара ГАТАУЛЛИНА (16 яшь) рәсеме,**
**Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы**

# Туган телем

И минем туган җирем,
Шат синдә һәрбер көнем.
Саф чишмә кебек моңлы,
Бар минем туган телем.

Тукайны шагыйрь иткән,
Гасырлар кичеп килгән.
Җаныбыз кебек саклыйк,
Аерылмыйк туган телдән!

# Сабан туенда

Беләсезме, без кайда?
Без бит Сабан туенда!
Матур калфагымны киеп,
Быел чыктым тагын да.

Капчык киеп йөгерәбез,
Кашыклап су ташыйбыз.
Күзне бәйләп, кайчы тотып,
Бүләк кисә кайсыбыз...

Рәхәтләнеп күңел ачтым
Сабантуй булган көндә.
Милли киемнәрең киеп,
Сабантуйга кил син дә!

**Зифа МОРАТОВА,**
**Кукмара, К.Ф. Шакиров исемендәге**
**Зур Сәрдек гимназиясе, 1 нче «А»**
**сыйныфы укучысы**



**Алия ШИҺАПОВА (15 яшь) рәсеме,
Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы**

# Нурын сибеп торсын исемебез

Бала туа. Сабый туганчы ук,
Әти-әни исем сайлыйлар.
Әби-бабай, туган-тумача да –
Һичберсе дә читтә калмыйлар:
«Нинди исем кушыйк улыбызга?»
«Кызыбызга монысы килешер!»
«Хан заманнан калган инде анысы,
Кеше көләр, үртәр бер ише.»
«Ә монысын бөтен халык куша,
Ятрак булсын, колакка ятыш.
Урысча да дәшкәч, үзгәрмәсен, –
Булсын урыс-татарча катыш.»
Менә шулай исем сайлый бар да,
Туа Ранель, Рафиль, Замирлар,
Миланалар, Миленалар үсә,
Зариналар, Адель, Самирлар…

Колакларга яңгырашы матур,
Мәгънәләре кемгә кирәк соң?
Төшенгәндә исем мәгънәсенә,
Вакыт узган – була инде соң.
Чын безнеңчә, үзебезчә итеп,
Кушсак иде милли исемнәр:
Зөләйхалар, Рәйхан, Минтимерләр,
Маһинурлар, Саимә, Гөлсемнәр.
Атам кушкан изге бүләк исем,
Милли йөзнең алтын ачкычы.
Шәҗәрәдә нәселләрнең җебе,
Буыннарның сынмас баскычы.
Нурын сибеп торсын исемебез,
Татарлыкны горур яңгыратып.
Яшик әле бердәм, тату булып,
Татар телен сөеп-яратып!

Ирина **ХӘМИДУЛЛИНА,**
**Чистай, Гаделша мәктәбе укытучысы**

# Дуслык

Нурзия Мирхазова сүзләре,
Наилә Яхина көе




*Бөтендөнья балалары,*
*Кулларга алып каләм,*
*Татулык билгесе итеп,*
*Ясады яшел әләм.*

***Кушымта:***
*Дуслыкның яшел байрагы*
*Үскәч тә онытылмас.*
*Мәңге балкыр күгебездә*
*Татулык дигән кояш!*

*Әләмне мәйданга элдек,*
*Нур чәчә тирә-юньгә.*
*Дуслар белән тату гына*
*Уйнарга кирәк бергә.*

***Кушымта.***

# КЫЧЫТКАН АШЫ

БҮГЕН БЕЗДӘ КУНАКТА – ХАЛЫКАРА КОНКУРСЛАР ЛАУРЕАТЫ, КАЗАН ШӘҺӘР ФИЛАРМОНИЯСЕ СОЛИСТЫ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР ФИЛАРМОНИЯСЕ КАРШЫНДАГЫ БАЛАЛАР ФИЛАРМОНИЯСЕ ВОКАЛ АНСАМБЛЕ ҖИТӘКЧЕСЕ, КАЗАНДАГЫ 23 НЧЕ МУЗЫКА МӘКТӘБЕ УКЫТУЧЫСЫ ГӨЛНАЗ ГАФУРОВА.

Гөлназ Гафурова Түбән Камада туып үсә. Мәктәпне тәмамлагач, Казан музыка училищесында һәм Казан дәүләт консерваториясендә белем ала. Казан музыка училищесында укыганда булачак ире Вәли белән таныша. Алар гаиләсендә хәзер ике бала – Мөхәммәт белән Җәннәт үсеп килә.

– Без үскәндә әнинең өстәлләре тәмнүшкәләрдән сыгылып тора иде. Хәзер дә безне сыйлап кына тора. Әти-әнием бик кунакчыл кешеләр, аларга кунаклар бик еш килә. Әниемнән күреп мин дә кунаклар кабул итәргә, пешеренергә яратам. «Сеңелем белән беренче мәртәбә пешергән өчпочмаклар истә калган – шакылдап тора иделәр, әмма әти йөзен дә чытмады, мактый-мактый ашады. Шул мактаулар миңа канат куйды, үсендерде, – ди Гөлназ. – Ә бүген мин журнал укучыларына май ае кычытканыннан аш пешереп күрсәтәсем килә».



***Кычыткан ашы өчен кирәкле ингредиентлар:***

**300 гр кычыткан,**
**3 литр шулпа,**
**4-5 данә йомырка,**
**1 аш кашыгы тоз,**
**2 баш кишер,**
**1 баш суган,**
**100 гр атланмай,**
**2-3 баш бәрәңге.**

## Җиде сорау

1 ***– Татар хатыны пешерә белергә тиешле өч ризык?***

– Татар хатын-кызы бәлеш, өчпочмак һәм коймак пешерә белергә тиеш дип уйлыйм.

2 ***– Татар ир-аты яраткан өч ризык?***

– Татар ир-аты дигәндә, мин иң элек әтиемне һәм иремне күз алдында тотам. Әти минем итле ризыкларны ярата. Бер елны гөмбә бик күп булды, җиде чиләк җыйдык, тозладык та, маринадладык та, кыздырдык та... Кыскасы, шул елны ит урынына гөмбә ашадык. Әти түзмәде: «Тәмле булса, гөмбәне бүре дә ашар иде», – дип куймасынмы... Ә Вәли безнең чәй эчәргә ярата, аннары балык, манты...

3 ***– Ир-ат йөрәгенә юл ашказаны аша, дигән сүз белән килешәсеңме?***

– Килешәм. Гомумән, һәр кеше тәмле пешерелгән ризыкны, мул өстәлләрне ярата инде ул. Кунакны мул өстәл белән каршы алу – татар халкына хас матур сыйфат.

4 ***– Балачак нинди ризык белән хәтереңә уелып калды?***

– Әнинең коймаклары, токмачлы ашы, бәлешләре – ашап туйгысыз. Без үскәндә әни бик еш «Графские развалины» дип аталган бизе-торт пешерә иде. Аның тәмлелеге! Бүгенге көндә дә кунакка керә башласак (без янәшә яшибез), сорап пешертәм.

5 ***– Гастрольләрдә йөргәндә кайсы якта нинди милли ризыклар белән сый-***



***лыйлар? Моңарчы күз күрмәгән, ят ризык ашаганың булдымы?***

– Һәр якның үз ризыгы бар һәм ул үзенчә тәмле. Казахстанда эчкән чәйнең тәме әле дә истә. Чәйгә чәй кашыгы белән каймак, акмай яисә сарымай салып бирәләр, вәт тәмле!

**6** ***– Көннәрдән бер көнне Гөлназ Гафурова ресторан ачса, фирменный ризыгың нәрсә булыр иде икән?***

– Дөрес туклану ресторанын ачар идем. Менюда парда пешкән ризыклар, күбрәк яшелчәләр булыр иде. Без өйдә дә дөрес һәм файдалы ризыклар белән тукланырга тырышабыз. Ярты ел хәтта ит тә ашамадык, чистарындык, җиңеләйдек. Хәзер дә мин күбрәк балык ашарга, ашларны вегетарианнарча пешерергә тырышам. Щи, борщ итсез дә бик тәмле килеп чыга.

**7** ***– Француз мәкале: хатын-кыз юктан да скандал, салат һәм эшләпә ясый белә, ди. Эшләпә ясый аласыңа ышанам, ә скандал белән салат ясый алыр идеңме? Ул юктан гына ясалган салатның рецепты ничек?***

– Скандалны ясый белмим, ә менә салатны рәхәтләнеп ясыйм. Балаларыма да: «Күңел җылыңны кушып, үз кулларың белән пешергән, ясаган ризык кибетнекенә караганда тәмлерәк була», – дип өйрәтәм. Үзем яратып ясый торган салатның рецепты белән уртаклашыйм әле. Аңа помидор, кызыл борыч, пешкән яисә ысланган тавык ите, кыяр, морковча, тәменчә тоз, кара борыч һәм каймак яисә майонез салып болгатырга кирәк.



1. Иң элек яшь кычыткан-ны җыеп кергәч, кайнар су белән пешеклибез. Итле аш кирәксә, шулпа-сын алдан пешереп куя-быз. Мин үзем итсез генә пешерәм



2. Табага атланмай салып эретәбез. Аңа баштан суган, аннары, угычтан кишер уып, кыздырабыз



3. Өстенә бәрәңге турап салабыз



4. Барысы да кызгач, табадагы яшелчәләрне итле шулпага яисә кайнаган суга салып 20 минутлап пешерәбез



5. Өстенә туралган кычытканны салабыз да тагын 10 минут пешерәбез



6. Пешеп чыккан ашны тәлинкәләргә бүлгәндә пешкән йомыркаларны урталай бүлеп, шулпага салып чыгарабыз. Түбәнчә яшел суган, әнис турап салабыз


***Ашларыгыз тәмле булсын!***

Фоторәсемнәр Гөлназ Гафурованың шәхси архивыннан

# Шахворд

Беренче таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән, шахмат фигурасы – атның дөрес йөреш тәртибен кулланып, Фәнис Яруллинның Сабантуй бәйрәменә багышланган шигъри юлларын укыгыз!

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | , | т | ы | ү | ш | е | к | е |
| у | р | Б | Э | г | н | г | л | р |
| : | н | й | й | ә | д | а | н | у |
| а | к | Б | н | б | ө | й | м | ә |
| а | а | м | а | | ш | а. | й. | б |
| ә | б | а | | а | р | | р | ә |
| г | б | н | ә | 72 | | л | е | 38 |
| ң | р | С | а | н | и | д | й | е |
| а | н | е | з | ә | д | ң | Т | з |



**Шахмат аты «Г» хәрефе буенча йөри**

**Шахвордның җавабы – саннарда**

Бер сан бер хәрефкә туры килә. Шигъри юллар 76 хәрефтән тора.

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 19 | 16 | 33 | 2 | 21 | 48 | 35 | 4 |
| 17 | 32 | 1 | 20 | 47 | 34 | 3 | 22 | 49 |
| 58 | 15 | 18 | 45 | 60 | 75 | 66 | 5 | 36 |
| 31 | 44 | 59 | 74 | 65 | 46 | 61 | 50 | 23 |
| 14 | 57 | 64 | 71 | | 67 | 76 | 37 | 6 |
| 43 | 30 | 73 | | 69 | 62 | | 24 | 51 |
| 56 | 13 | 70 | 63 | 72 | | 68 | 7 | 38 |
| 29 | 42 | 11 | 54 | 27 | 40 | 9 | 52 | 25 |
| 12 | 55 | 28 | 41 | 10 | 53 | 26 | 39 | 8 |

**Шахвордның җавабы:**

Бүген бездә Сабантуй,
Эшләреннән барын куй.
Тизрәк йөгер мәйданга:
Бәйрәм башлана анда.

**Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем фәннәре академиясе (ХПБФА) академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде**

# Истәлекле даталар
# 2021

## ИЮЛЬ

**1 июль**
Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Любовь Григорьевна Гриценкога 60 яшь (1961)

**6 июль**
Татарстан Республикасы Халык уен кораллары дәүләт оркестрының сәнгать җитәкчесе, дирижёры, ТАССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Анатолий Иванович Шутиковка 75 яшь (1946)

**7 июль**
Композитор, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясеның атказанган сәнгать эшлеклесе Рафаил Мулланур улы Бакировка 75 яшь (1946)

**8 июль**
Җырчы, педагог, ТАССРның халык артисты Рафаил Әхәт улы Сәхәбиевнең тууына 70 ел (1951-2019)

**10 июль**
Татарстан Республикасының С. Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залы оештырылуга 25 ел (1996)

**15 июль**
Актриса, педагог, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Асия Хәсән кызы Хәйруллинаның тууына 100 ел (1921-2004)

**19 июль**
Рәссам-график, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Зифа Васил кызы Мөхәммәтҗанованың тууына 70 ел (1951-2016)

## АВГУСТ

**5 август**
Рәссам, график, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Надир Усман улы Әлмиевкә 75 яшь (1946)

**5 август**
Оркестр артисты һәм концертмейстер, Татарстан Республикасының халык артисты Фәрид Зөфәр улы Шиһаповка 70 яшь (1951)

**12 август**
Актриса, ТАССРның халык артисты Мәрзия Галимбай кызы Миңлебаева (Хәмитова)ның тууына 110 ел (1911-2000)

**15 август**
Театр һәм гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, педагог, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Әлфия Әнвәр кызы Җәмиловага 70 яшь (1951)

**16 август**
Композитор һәм пианист, СССРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы Яхинның тууына 100 ел (1921-1993)

**18 август**
Актёр, язучы, Татарстан Республикасының атказанган артисты Шамил Тимергали улы Фәрхетдиновка 50 яшь (1971)

**20 август**
Композитор, җырчы, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Рәшит Фарук улы Абдуллинның тууына 70 ел (1951-2004)

**23 август**
Актриса, Татарстан Республикасының халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты Дания Нургаяз кызы Нуруллинага 75 яшь (1946)

## СЕНТЯБРЬ

**5 сентябрь**
Сынчы, рәссам, график, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марина Викторовна Нигъмәтуллинага 60 яшь (1961)

**6 сентябрь**
Шагыйрә, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Флёра Сабирҗан кызы Гыйззәтуллинага 90 яшь (1931)

**8 сентябрь**
Актёр, режиссёр, педагог, Башкортстан АССРның, РСФСРның, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның халык артисты, Башкортстанның С. Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе, Россиянең Дәүләт премиясе лауреаты Рифкать Вәкил улы Исрафиловка 80 яшь (1941)

**29 сентябрь**
Актёр, режиссёр, педагог, ТАССРның, РСФСРның, СССРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәлил Гали улы Әбҗәлиловның тууына 125 ел (1896-1963)

**(Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре = Календарь знаменательных и памятных дат. 2021 / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Г.Ш. Җомаголова; мөх-рләр И.Г. Һадиев, А.Р. Габделхакова. – Казан: Милли китап, 2020. – 168 б.)**